КӨНДЕЗ – УКЫТУЧЫ, КИЧ...

Илдә яшәүчеләрнең 42 процентының өстәмә керем чыганагы бар

> 4

ФӘЙРҮЗӘ МӘҖИТОВА:

«Бу өлкә кешеләре адреналинсыз яши алмый»

> 5

БӘХЕТ КАЙДА?

Хәбибрахмановлар аны балаларында күрә

> 6

ТИНЧУРИНДА – ПРЕМЬЕРА

Татар театры сәхнәсендә беренче тапкыр куелган рэп-опера нигә шау-шу куптарды?

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 37 (29197) | Сишәмбе | 26 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илнар ХӨСНУЛЛИН

МИЛЛИОННАР КАЙГЫСЫ

МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ФАҖИГА БЕЗНЕ НӘРСӘГӘ ӨЙРӘТЕР?

Кем? 22 март кичендә Мәскәү өлкәсендә булган куркыныч вакыйгадан соң төп сорау әнә шул. Террорчылар «Крокус Сити Холл»да 500 мең сум акча өчен 100дән артык кешенең гомерен өзде. Аларга канлы әмер бирүчеләрнең табыласы шик уятмый. Тагын бер сорау бар: без нинди сабак алырбыз?

«Татар-информ»

Йокысыз төн

Күз алдында булгач, тагын да куркынычрак. Җомга көн кич белән булган коточкыч вакыйганы ил халкы телевизор, интернет сайтлары һәм социаль челтәрләр аша күзәтеп барды. Туры эфирда дип әйтергә мөмкин. Иң аянычы: барысын да күреп торасың, ә ярдәм итеп булмый.

Фаҗига кичке сәгать 8ләр тирәсендә башланды. Террорчыларның «Крокус Сити Холл»ны махсус сайлаганы күренеп тора: биредә танылган төркемнең концертына меңләгән кеше җыелган. Тамаша башланырга берничә минут кала аларга кораллы кешеләр һөҗүм итә. Бернинди таләпләре юк, боларга заложниклар да кирәкми. Бала-чага, яшь-җилкенчәк, өлкәннәр – барысын да рәттән кырып баралар. Ул гына да түгел, бинага ут төртәләр. Берничә сәгать дәвам иткән янгын башлана. Меңләгән кеше ничек тә булса качып котылу ягын карый. Әмма барысы да өлгерә алмый. Ничәсенең ятып калганы әлегә төгәл билгеле түгел. Куркыныч саннар күңел ачу комплексы булган урынны җыештырып бетергәч кенә билгеле булачак.

Шимбәгә каршы төндә бик азлар гына йоклагандыр. Ә иртән Брянск өлкәсендә 4 кешенең тоткарлануы турында билгеле булды. Кулына корал тотып, йөздән артык кешене үтергән адәм актыклары Украина ягына чыгып качарга маташкан. Аларны чик буенда көтеп торганнар дигән фараз да бар. Шунысы төгәл билгеле: барысы да Урта Азиядәге бер илдән килгәннәр. Сабыйларга ут ачучыларның берсе – үзе 4 бала атасы. Араларында 19 яшьлеге дә бар. Сорау алганда аларның берсе бу җинаятьләре өчен 500 мең сум акча вәгъдә иткәннәрен әйтә. Соңрак ачыкланды: бу акча аларның дүртесенә булган икән. Кеше гомере турында сүз бара. Рәсми хәбәрләргә караганда, шимбә көнне барлыгы 11 шикле кеше тоткарланган.

Җәзасын алачаклар

Әлеге вакыйга турында Россия Президентына баштан ук хәбәр итеп бардылар. Владимир Путин коткаручылар, табиблар, хокук сакчыларының ничек эшләгәнен белеп торды. 23 мартта дәүләт башлыгы ил халкына мөрәҗәгать итте. Владимир Путин әйтүенчә, әлеге терактка җентекләп әзерләнгәннәр. «Җинаятьчеләр салкын канлы, максатчан рәвештә нәкъ менә гражданнарыбызны, балаларыбызны үтерергә, атарга дип барган. Заманында оккупацияләнгән территорияләрдәге нацистлар кебек, алар кеше алдында җәзаларга, канлы куркыту акциясе оештырырга ниятләгән», – диде ул. Россия Президенты сүзләренә караганда, бу җинаятьне кылучылар, аны оештыручылар һәм заказ бирүчеләр гадел һәм котылгысыз җәзасын алачак. Дәүләт башлыгы әйтүенчә, террорчыларны, үтерүчеләрне, милләте булмаган һәм була алмаган бәндәләрне бер генә язмыш көтә – үч алу һәм оныту. Аларның киләчәге юк. «Хәзерге вакытта безнең, фронттагы хәрбиләрнең һәм илнең барлык гражданнарының уртак бурычы – бер сафта бергә булу, – диде ул. – Россия күп тапкырлар авыр, кайвакыт түзә алмаслык сынаулар аша үтте, әмма алар аны тагын да көчлерәк кенә итте. Хәзер дә шулай булачак». 24 мартта ил күләмендә матәм көне игълан ителде.

Уртак кайгы

Республика да әлеге фаҗигадән читтә калмады. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Мәскәү өлкәсе губернаторы Андрей Воробьев һәм Мәскәү мэры Сергей Собянинга кайгы уртаклашу телеграммалары юллады. Парламент депутатлары һәм үзе исеменнән кайгы уртаклашу сүзләрен Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җиткерде. Халык күп катнаша торган чаралар уздырмау турында карар чыкты. Хөкүмәт йортында узган киңәшмәләр Мәскәү өлкәсендә гомере өзелгән кешеләрне искә алудан башланды.

Ахыры 3 нче биттә >

20 меңнән арткан

Ел башына Татарстанда уртача пенсия күләме 20627 сум тәшкил иткән. Россия Социаль фонды мәгълүматларына караганда, республикада ир-атларның пенсиясе хатын-кызларныкына караганда зуррак күләмдә. 2024 ел башына ир-атлар – уртача 19368, ә хатын-кызлар 19017 сум күләмендә пенсия алган. Республикада барлыгы 1094460 пенсионер теркәлгән. Шуның 207044е эшли.

Шул ук вакытта быел гыйнвар аенда Идел буе федераль округында пенсиянең уртача күләме 20178 сум тәшкил иткән. Округта барлыгы 8529604 пенсионер яши, шуның 1479482се рәсми төстә эшли.

Гомумән, Россиядә быел гыйнвар аенда пенсиянең уртача күләме 20781 сум булган. Иң зур пенсия – Чукотка автономияле округында. Биредә пенсионерлар аена уртача 33392 сум ала. Татарстандагыга караганда 38 процентка зуррак сан бу. Ә инде иң аз пенсия алучылар Дагыстанда яши. Биредә аның күләме – 15293 сум.

Отышлы сәүдә

Узган шимбәдә Казанда һәм Татарстанның башка шәһәрләрендә авыл хуҗалыгы ярминкәләре узды. Соңгы ике атнаның шимбә көннәрендә барлыгы 141,5 миллион сумлык продукция сатылган.

Исегезгә төшерәбез: 16 марттан республикада авыл хуҗалыгы ярминкәләре эшли башлады. Сәүдә Казанда –14 мәйданчыкта, Чаллы һәм Яшел Үзән районында – 2шәр, Түбән Камада – 3 урында, шулай ук муниципаль районнарда оештырыла.

Шулай итеп, соңгы ике ярминкәдә 210,8 тонна яшелчә (шул исәптән 115,4 тонна бәрәңге), 36,5 тонна сөт, 89,6 тонна шикәр комы, 460 мең данә йомырка, 181 тонна ит сатылган.

Ярминкәләр уздыру өчен барлыгы 33 район һәм 1548 берәмлек транспорт җәлеп ителгән. Татарстанда язгы ярминкәләрне 28 апрельгә кадәр үткәрү күздә тотыла.

Диктант язабыз

«Җиңү диктанты» бөтенроссия акциясе 26 апрельдә уздырыла. Быел инде алтынчы тапкыр оештырылачак ул.

Россия хәрби-тарихи җәмгыяте хәбәренә караганда, чарада катнашучылар Бөек Ватан сугышы тарихы буенча тестлар узачак. Быел диктант биремнәре Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итүгә 80 ел тулуга, фронтовик язучылар юбилеена, шулай ук башка юбилей даталарына багышлана. Акциядә, яшькә бәйсез рәвештә, теләсә кем катнаша ала.

Диктант язу урыннары илнең барлык 89 төбәгендә, шулай ук 50 чит дәүләттә ачылачак. Сораулар 5 телгә: инглиз, француз, гарәп, кытай һәм испан телләренә тәрҗемә ителә. Мәскәүнең Поклон тавындагы Җиңү музее, гадәттәгечә, акциянең үзәк мәйданчыгына әйләнә.

Чараны оештыручылар диктантка әзерләнү өчен 8 округта ачык лекцияләр уздыруны күздә тота. Моннан тыш мультимедиа күргәзмәләр һәм цифрлы экскурсияләр оештырылачак. Порталдагы (Диктантпобеды.РФ) күнегү-тестлар да акциягә әзерләнергә ярдәм итәчәк.

Сүз уңаеннан, узган елда «Җиңү диктанты»н илебезнең 85 төбәгендә һәм 46 чит илдә барлыгы 1,9 миллионнан артыграк кеше язган.

Карлы яңгыр көтелә

Татарстанда, төньяктан циклон үтеп керү сәбәпле, һава шартларының начараюы көтелә. Гидрометеорология идарәсе хәбәренә караганда, чәршәмбе – 27 мартта көчле явым-төшем: көнбатыш районнарда – җепшек кар, көнчыгышта карлы яңгыр булачак. Шулай ук секундына 15–20 метр тизлектә төньяктан көчле җил, кыска вакытлы буран булыр дип фаразлана. Юлларда бозлавык, урыны белән кар көртләре. Көндез термометрның терекөмеш баганасы 0…+5, төнлә –3…+2 градус күрсәтәчәк.

Пәнҗешәмбе – 28 мартта җепшек кар, төньяк-көнбатыштан секундына 15–18 метр тизлектә җил, кыска вакытлы буран. Җомга – 29 һәм шимбә – 30 мартта явым-төшем фаразланмый. Көндез +3…+8, төнлә –3…–8 градус.

26–28 мартта республикада явым-төшем күләме көнбатыш районнарда – айлык норманың 30–50 процентын, төньяк һәм көнчыгыш районнарда 100 процентын һәм аннан күбрәген тәшкил итәчәк.

Яңалык

Бушлай торак: кемнәр өметләнә ала?

Ятимнәр, аз керемгә ия булучы күпбалалы гаиләләр, хәрби хәрәкәтләр инвалидлары һәм ветераннары торак сатып алуда дәүләт ярдәменә таянырга мөмкин дип яза «Парламентская газета».

Халык торак шартларын төрлечә яхшырта. Кемдер фатирын зуррагына алыштыра, кемдер ипотекага торак сатып ала. Ә инде бу мәсьәләне берничек тә хәл итү мөмкинлегенә ия булмаганнарга дәүләт булыша. 2024 елда мондый ярдәмгә кемнәр өметләнә ала?

Иң элек аз керемле күпбалалы гаиләләр, шул исәптән ялгыз аналар. Исегезгә төшерәбез: балигълык яшенә җитмәгән өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр күпбалалы булып санала. Бушлай торак алучылар исемлегендә шулай ук 23 яшькә кадәрге ятимнәр дә (торакны мирас итеп алмаган булсалар) бар.

Түләүсез куыш гаиләдә бер кешегә туры килә торган уртача керем күләме төбәктәге яшәү минимумыннан кимрәк булган очракта бирелә. Тагын бер шарты – гаилә үз төбәгендә кимендә биш ел яшәгән булырга тиеш. Ә инде торак шартларын үзләре үк начарайткан, әйтик, мөлкәтен саткан, фатирына тагын кемнәрнедер теркәгән кешеләр дәүләт ярдәменә өметләнә алмый.

Бик нык тузу сәбәпле, төзекләндереп булмый торган йортларда (авария хәлендә дип танылган торакта) яшәүчеләр дә дәүләт хисабына яңа фатир юнәтергә мөмкин.

Ләкин яңа торакка дәгъва кылучыларга, сабырлыкны җыеп, бераз чиратта торырга туры киләчәк. Ә инде чиратка басу өчен, гариза һәм кирәкле барлык документларны тапшырасы була. Гадәттә бу – гаилә әгъзаларының паспортлары, балаларның туу турында таныклыклары, никахлашу турында таныклык, гаиләне аз керемле дип тану турында, эш урыныннан белешмәләр, күпбалалы гаилә статусын раслаучы таныклык. Гариза һәм документларны Күпфункцияле үзәк яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша тапшырырга мөмкин.

Дәүләт фатир мәсьәләсен башка ысуллар белән дә хәл кылырга ярдәм итә. Халыкның билгеле бер категорияләренә исәпләнгән төрле программалар булдырылган. Шуларның берсе – «Яшь гаилә». Дөрес, бу очракта торакның бер өлешен сатып алырга туры киләчәк. Дәүләт мондый программа буенча яшь гаиләләргә (ир яки хатын 35 яшькә кадәр булырга тиеш) субсидия бирә. Балалы гаиләләргә исә ире яки хатыны Россия паспортына ия булмаган очракта да ярдәм ителә. Шулай ук ялгыз аналар (аталар) мондый мөмкинлектән файдалана ала. Дәүләт ярдәме күләменә килсәк, әле бәби алып кайтырга өлгермәүчеләргә – торак бәясенең 30 проценты, балалыларга – 35 проценты күләмендә.

Дәүләт Думасының Хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эшләре буенча комитеты рәисе Ярослав Нилов әйтүенчә, закон нигезендә, хәрби хәрәкәтләр инвалидлары һәм ветераннары да торак алуга хокуклы. 2005 елга кадәр федераль чират гамәлдә булып килгән. 2005 елдан башлап, чиратны төбәкләрдә төзиләр. Моның өчен федераль бюджетта акча карала.

Сүзгә-сүз

2024 гаилә елы

Минтимер ШӘЙМИЕВ:

Мин ишле гаиләдә тугызынчы бала булып дөньяга килгәнмен. Күпбалалы гаиләләр Әнәк авылында (Актаныш районы) бер безнеке генә түгел иде, әлбәттә. Гомумән, ишле гаиләдә бала тырыш, шәфкатьле, кече күңелле булып үсә. Оядагы – дөньяда, диләр бит. Җәмгыятебездә үрнәк булырлык сыйфатлар.

(«Сөембикә» журналы, 1996 ел)

РОССИЯЛЕЛӘР БӘХЕТЛЕМЕ?

ВФокусе Mail.ru һәм Здоровье Mail.ru проектлары ил халкыннан бәхетлеме-юкмы икәнен белешкән. Сораштыруда катнашучыларның 84 проценты өчен «бәхет» төшенчәсе үзенең һәм якыннарының сәламәтлеге икән. Күпчелек (69%) көндәлеге тынычлыкны да бәхет дип саный.

69% үзен бәхетле кеше дип саный

16% үзен бәхетсез дип саный



14% җавап бирергә кыенсынган

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ШАТДАУННАН КОТЫЛУ

Вәкилләр палатасыннан соң, АКШ Сенаты, шатдаунга берничә сәгать вакыт калгач кына, 1,2 триллион долларга тиң булган бюджетны кабул итте. Бюджет кабул ителмәсә, ил хөкүмәте эштән туктарга, бар нәрсәнең асты өскә килергә тиеш иде. Канун проектын яклап, 74 сенатор тавыш бирде, 24 сенатор каршы чыкты. Тавыш бирү 23 мартта төн уртасында тәмамланды. Сенаторларның шуннан соң да сузарга мөмкинлеге юк иде, чөнки закон кабул ителмәсә, Дәүләт департаменты, Эчке эшләр һәм Оборона министрлыклары, сәламәтлек саклау һәм социаль тармаклар, мәгариф өлкәсе – барысы да акчасыз каласы иде. Бюджет кабул итүне алар соңгы елларда гел шулай бәхәсле мәсьәләгә әйләндерәләр, чөнки дәүләт бурычлары чиктән ашты һәм түләп бетерә алмаслык хәлгә килде. Шуңа күрә республикачылар белән демократлар казна тирәсендә биюне зур тартышка әйләндерәләр. Һәрберсе үз максатларын алга сөрә. Бюджетның елдан-ел кысыр калуы, тишекләрне томалау өчен акча табу кыенлыгы дөньяның иң куәтле державасының халыкара мәйданда йогынтысын киметә. Африка дәүләтләре Сэм агайга һәм башка Көнбатыш державаларына артлары белән баса, Вашингтон белән Брюссель арасында каршылыклар барлыкка килә, Кытай белән тартыш кыенлаша… Шатдаун куркынычы алдында торган Ак йорт, мәсәлән, берничә ай дәвамында Украина конфликтын финанслый алмады. Нәтиҗәдә Россия гаскәрләре тактик өстенлеккә иреште. Сенат канун проектын яклап тавыш биргәч, АКШның хәрби транспорт самолетлары Польшага Украина армиясе өчен күпләп корал ташый башлады дигән хәбәрләр күренде.

Америка төбәк конфликтлары өчен гадәттән тыш күп акча тота. Бөек держава роле бик кыйбатка төшә. Кайчандыр СССР шул тырмага басып башын ярган иде. Кризис көчәйгән саен, Вашингтонга дөнья масштабында дилбегә кагу кыенгарак киләчәк һәм бу көчләр чагыштырмасын үзгәртәчәк.

Глобаль кризис исә нык үсешкә ирешкән илләрнең барысын да дер селкетә. Канаданың төп инглиз телле газетасы «National Post» үткән атнада, хөкүмәтнең яшерен отчетына нигезләнеп, гражданнар үзләренең икътисадый хәлләре өмтесез икәнен аңлауга, илнең зур буталышлар чорына кереп китәчәге турында язды. Ул отчетта: «Якынлашып килүче рецессия тормыш дәрәҗәсен кискен түбәнәйтәчәк», – дигән сүзләр бар икән. Якындагы биш елда хәл бик начарланачак, дип кисәтә хөкүмәт аналитиклары. Искә төшерик: Канада – мигрантларга зур социаль пособиеләр түли торган илләрнең берсе. Киләчәктә бу «җимлек» ябылырга тиеш.

Европада да шуңа охшаш хәлләр күзәтәбез. Кытай икътисады да авыр сулый. Планетакүләм шатдаунга якынлашабыз.

Россиядә

СУГЫШ ХӘЛЕНДӘ?

«Крокус Сити Холл»дагы террор акты иминлек мәсьәләсенең россиялеләр өчен дә катлаулыга әйләнеп баруын искәртә. Дөньякүләм зур яңгыраш биргән әлеге вәхшилек акты сорауларны күп уята. 7 март көнне американнар һәм европалылар Россиядәге үз гражданнарын кичекмәстән кайтып китәргә, халык күп җыелган урыннарга бармаска чакырганнар һәм массакүләм чаралар уздырылган урыннарда, концертларда канлы террактлар булачагын фаразлаганнар иде. Илон Маск хәтта 11 сентябрь масштабыннан да зуррак һөҗүм булачагын искәртте. Дөрес, атаклы инвестор һөҗүм урынын Россия дип үк әйтмәде кебек әйтүен… Ләкин төрек газетасы «Hürriyet» сүзләре белән әйтсәк: «… Россияне аның тарихындагы иң күп үлемле террорчылык актларының берсе тетрәтте».

Вәхшилек тормышка ашырылыр алдыннан гына Путин сүзчесе Песков «Аргументы и факты» атналыгына: «Без сугыш хәлендә. Әйе, бу махсус хәрби операция буларак башланган иде, әмма… күмәк Көнбатыш Украина ягыннан катнашучыга әверелү белән, безнең өчен сугышка әйләнде», – диде. Дөрес, соңрак ул «Коммерсантъ»ка махсус хәрби операциянең юридик статусы үзгәрмәвен әйтте, әмма анда да чынлыкта сугыш баруын таныды.

Көнбатыш гаскәрләренең әнә-менә Украинага кертелергә торуын искә алганда, хәл, чынлап та, катлаулы.

Илне санкцияләр белән көчсезләндерү омтылышы да арта. Аркадаш илләр дә АКШ басымына чыдый алмый. Кытай банклары Россия белән ике арада акча йөртүне туктата. Дәүләт Думасының Финанс базарлары буенча комитеты җитәкчесе Аксаков моны «трагедия түгел» дип бәяләде, ләкин озатылган чимал акчасы ике айга кадәр соңга калып керә башлады инде. Һиндстан Россия нефтеннән баш тартты. Башка илләр дә «Совкомфлот» танкерларын кабул итүдән курка дигән хәбәрләр бар. Әлегә Кытай коткара, соңга калып булса да акчасын да түли. Фронт сызыгы сәүдә терминаллары аша да үтә бит монда. Шуңа күрә каршы якны сөйләшүләр өстәле янында җиңәргә тырышырга кирәк булачак. Компромисслар таләп итсә дә, җиңүнең иң отышлы юлы шул.

ФӘН БЕЛӘН МӘДӘНИЯТНЕ НИЧЕК ДУСЛАШТЫРЫРГА?

tatarstan.ru

Бер карасаң, бу ике өлкә берберсенә бөтенләй ят кебек. Ләкин фән – мәдәниятсез, мәдәният фәнсез була алмый. Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советының чираттагы утырышы әнә шул турыда иде.

Һәркем үз казанында гына. Республикада милли үзаң, традицияләрне саклау, киләчәк буыннарга тапшыру мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренүләр уздырылып тора. Әмма Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, аларның нәтиҗәләре дивар артында кала. «Бу эштә таркаулык сизелә. Тикшеренү нәтиҗәләре бердәм ачык фәнни базага җыелмый, шуңа да алар нәтиҗәле итеп кулланылмый. Фәнни конференцияләр тематикасында да система юк. Тематика артык тар булгач, кагыйдә буларак, алар җәмгыять тарафыннан да кызыксыну, резонанс тудырмый», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Музыкаль мирас. Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова сүзләре белән әйтсәк, Идел һәм Урал буеның урта гасыр музыкаль мирасын торгызырга кирәк. Белем җитәрлек, гамәлләргә күчсәк була. Бу өлкәдә төп проблемаларның берсе – милли музыка уен коралларына игътибар җитмәү. Әлеге проблема безнең милли проектлар кысасында да еш телгә алынды. Ниһаять, Казандагы Үзәк универмаг (ЦУМ) бинасында ачылачак халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре үзәгендә халык уен кораллары җитештерү остаханәсе булдырырга ниятлиләр. «Әлеге остаханәдә тальян, курай, думбра, гөслә, ятаган, дәф кебек уен кораллары җитештерү күз уңында тотыла. Моннан тыш, Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә республикадагы осталар турындагы мәгълүмати базаны яңарту да планлаштырыла», – диде министр.

Цифрлаштыру. Хәзерге вакытта республика музейларында – 2 миллионнан артык, китапханәләрдә 23 миллионнан артык берәмлек исәпләнә. Сан ягыннан без – Идел буе федераль округында беренче һәм икенче урыннарда. «Ләкин глобаль цифрлаштыру шартларында без әлегәчә фондларыбызның тулы исәбен һәм тасвирламасын булдыра алмадык. Моны системага салу бурычын куябыз», – диде Ирада Әюпова.

«Яшь» кадрлар мәсьәләсе бу очрашуда да күтәрелде. Ирада Әюпова музейларга «бай мирасыбызны өйрәнә һәм анализлый алырлык» яшь галимнәр җитмәвен ассызыклады. Бу проблеманы югары уку йортлары белән берлектә, шул исәптән, максатчан уку программасын кулланып чишәргә тәкъдим итте.

Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов та бу мәсьәләгә аерым тукталды. «Хәзерге вакытта академиядә тарих, әдәбият һәм филология юнәлешендә 277 кеше эшли. Ләкин галим һәм тикшеренүчеләрнең уртача яше 60 яшькә якынлаша. Буыннар алмашын тәэмин итү өчен махсус программа кирәк», – диде ул. Рифкать Миңнеханов тагын бер мактанасы килми торган статистика белән таныштырды. Соңгы дүрт елда республика буенча фәнни кадрлар әзерләп чыгару 12 процентка кимегән. Иң зур процентлар мәдәнияткә бәйле өлкәләргә туры килә. Болай дәвам итсә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсе галимнәрен әзерләү системасы бөтенләй юкка чыгарга мөмкин.

Ясалма интеллект. Дошманмы ул, чиксез мөмкинлекләр ачучымы? Бу турыда сөйләшкәндә, Татарстан Рәисе: «Ясалма интеллектка салынып, без бөтенләй примитив җан ияләренә әйләнеп бетмәбезме? Хәзер күпләр тапкырлау таблицасын да белми бит», – дип, фикерләшү һәм берникадәр бәхәсләшү өчен җирлек тудырды. «Мәдәнияткә нигезләнгән тотрыклылык этик кыйммәтләрне сакларга мөмкинлек бирәчәк, һәм шуның хисабына без ясалма интеллект тудыра алырлык куркыныч тенденцияләрне контрольдә тота алырбыз дип уйлыйм», – диде бу җәһәттән Югары икътисад мәктәбенең дәүләт икътисады секторы үзәге директоры Татьяна Абанкина.

Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе Райнур Хәсәнов исә бу мәсьәләнең икенче ягы – ясалма интеллект мөмкинлекләрен татар телен үстерүдә файдалану турында сөйләде. Аның сүзләренчә, татар теле әлегә ясалма интеллект дөньясына тулысынча кереп китә алмады. «Әгәр без бу проблеманы хәл итсәк, татар теленең югалу куркынычы юкка чыгачак, телебез, киресенчә, киң үсеш алачак. Татар теле ясалма интеллект кулланылган өлкәләрдә төп телләрнең берсе булып танылa ала. Моның өчен безгә телебезне цифрлаштыруда һәм яңа технологияләр белән баетуда системалы рәвештә эшләргә, шул исәптән халыкара аренада татар телен тарату өчен чаралар күрергә кирәк», – диде Райнур.

***

Утырыш азагында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов тагын бер проблема турында искәртте. «Бүген татар мәдәниятенә кагылышлы фәнни тикшеренүләр алып баручы галимнәр диссертацияләрен бары тик рус телендә язарга тиеш. Сәбәбе – татар телендә антиплагиат программасы булмау», – диде Әхмәтов. «Ничек татар мәдәнияте буенча русча диссертация язарга мөмкин? Тузга язмаган хәл! Эшләргә кирәк, әлеге программаны булдыруны карарга кертергә кирәк», – диде бу хакта Татарстан Рәисе. Нәтиҗәдә әлеге программаны КФУга Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә эшләргә кушылды. Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, үзебезне һәм телебезне яратсак, фәнни хезмәтләр дә татарча язылырга тиеш!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

vk.com

Ирада Әюпова әйтүенчә, 2022 елда Казан дәүләт мәдәният институтында мәдәнияткә яңа технологияләр эшләүче прототиплау үзәге ачылган.

Чираттагы утырыш – 29 мартта

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының илле икенче утырышы 29 мартта узачак. Депутатлар 20 мәсьәлә, шул исәптән 9 республика законы проектын һәм 2 федераль закон проектын караячак, дип хәбәр итә парламентның матбугат хезмәте.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин көн тәртибендәге мәсьәләләрне карау алдыннан республиканың соңгы вакыттагы иҗтимагый-сәяси тормышында парламент депутатлары катнашында узган берничә мөһим вакыйганы билгеләп үтте. Ул Россия Федерациясе Президентын сайлау нәтиҗәләренә аерым тукталды. «Республикада сайлаулар югары оештыру дәрәҗәсендә законнарга тәгәл туры китереп уздырылды, – дип басым ясады Фәрит Мөхәммәтшин. – Безнең республикада сайлауда катнашучылар саны 84,6% тәшкил итте. Шулардан 88,74% тавыш Владимир Путинга бирелгән». Дәүләт Советы Рәисе республика халкына, парламентның депутатлар корпусына сайлау кампаниясендә актив катнашулары өчен рәхмәт белдерде.

Алдагы утырышка килгәндә, Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, көн тәртибенә 20 сорау кертелә. Беренче укылышта карау өчен 9 республика закон проекты әзерләнгән, шул исәптән төбәк салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында, Тукай районының Мартыш авылын бетерү турында, документларның мәҗбүри экземпляры, инвестицион эшчәнлек, автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге, физик культура һәм спорт, күпбалалы гаиләләргә, шулай ук педагогик хезмәткәрләргә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында законнарга үзгәрешләр кертә торган закон проектлары.

Утырышта депутатлар шулай ук парламентның контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысасында берничә мәсьәләне караячак: 2023 елда Татарстанда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад, 2023 елда Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында мәгълүмат, 2023 елда гражданлык җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында республика Иҗтимагый палатасы доклады, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы һәм Татарстаннан сайланган Россия Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатлары эшчәнлеге турында мәгълүмат.

ЧИРАТ – БАЛАГА

Борчыган мәсьәлә

Соңгы арада Россиядә яшүсмерләрнең банк карталары ярдәмендә кылынган җинаятьләр саны арткан. Әлегә рәсми саннар аталмаса да, белгечләр илнең әле бер, әле икенче төбәгендә мошенник корбанына әверелгән балалар саны арта, дип чаң суга. Депутатлар исә, андый аяныч очракларны киметү өчен, балага банкта үз исәп-хисап счетын булдырырга рөхсәт иткән, яшь чиген арттырырга тәкъдим итә.

Мошенникларның үзләренең кырын эшләренә яшүсмерләрне дә җәлеп итә башлавы турында бер язган идек инде. Күптән түгел төп башына утыртуның яңа юлын уйлап тапканнар. Схемасы түбәндәгечә: кырыгалдар социаль челтәр аша үсмергә үз исеменә банк картасы рәсмиләштерүен сорап яза, моның өчен аңа шактый күләмдә акча вәгъдә итә. Банк картасын кулга алгач, бала билгесез зат өйрәткән ысул белән аңа тапшырырга яки телефонга банкның онлайн кушымтасын йөкләтеп, аның логин-парольләрен мошенникка хәбәр итәргә тиеш була. Тегесе, үз чиратында, яшүсмер исеменә рәсмиләштерелгән картаны үз максатларында куллана, анда халыкны төп башына утыртып табылган акчаларын күчерә. Әле берничә көн элек кенә Ульяновск өлкәсендә 15 яшьлек малайга үзенең банк картасын 20 мең сумга «сатарга» тәкъдим иткән алар. Бәхеткә, малай бу хакта әти-әнисенә әйтеп өлгергән. Алар тиз арада полициягә гариза язган.

Россия Дәүләт Думасының Туризм һәм туризм инфраструктурасын үстерү буенча комитет рәисе урынбасары Наталья Костенко сүзләренә караганда, мошенниклар бу ысул белән күбрәк имин булмаган гаиләдә тәрбияләнүче балаларны төп башына утырта икән.

– Шуңа күрә балаларга банкта исәп-хисап счетын унсигез яше тулгач кына ачарга рөхсәт итәргә кирәк. Моны эшләгәндә банклар ата-анадан рөхсәт язуы таләп итәргә дә онытмасын иде, – ди депутат.

Әлегә исә 14 яше тулып, кулына паспорт алган һәр яшүсмер закон нигезендә банкта үз исеменә исәп-хисап счеты ача ала. Әмма моның өчен ата-анадан рөхсәт язуы кирәк. Чынлыкта, бу таләп кайбер банкларда гына төгәл үтәлә. «Халык фронты» хәрәкәте вәкилләре әнә шулай дип кисәтә. Күптән түгел бу уңайдан алар махсус тикшеренү уздырган. «Саклык банкы», «ВТБ», «Альфабанк» һәм «Газпромбанк»ның 14–18 яшьлек үсмерләргә ничек исәп-хисап счеты ачуларын тикшергән. Нәтиҗәдә телгә алынган банкларның берсе дә ата-анадан рөхсәт язуын алып килүне сорамаган.

«ВТ» юристы Булат Закиров сүзләренә караганда, әгәр 14 яше тулган бала мошенникка картасын үз куллары белән тапшырган булса, закон каршында да үзенә җавап бирәсе булачак.

– Бу очракта ул җинаять җаваплылыгына тартылырга мөмкин. Әгәр мошенниклар баланың картасын яшерен рәвештә, аңа белдертмичә кулланган булса, бу очракта аңа берни булмаячак, – дип ачыклык кертте юрист.

Сүз уңаеннан, шунысын да белеп тору зарур: 14–18 яшьлек үсмер үз исеменә күчерелгән барлык акчаларны (хезмәт хакы, стипендия, пособие, олимпиада һәм бәйгеләрдә җиңгән өчен бирелгән премия һ.б.) ничек тели шулай тота ала. Моның өчен ата-анасының, опекуны яки опекунлык органының рөхсәт бирүе кирәкми. Ә менә аның счетына күчкән мирас акчасын, пенсия, алимент, туендыручыны югалткан өчен түләнгән акчаларны ул әти-әнисе яки опека органы язмача рөхсәт биргән очракта гына тота ала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«Касперский лабораториясе»нең балалар онлайн куркынычсызлыгы юнәлеше җитәкчесе Андрей Сиденко фикеренчә, балага банк картасы алып бирү генә җитми, аннан дөрес итеп файдаланырга да өйрәтергә кирәк. Моның өчен ата-ана түбәндәге киңәшләрне истә тотсын иде.

1. Бала банк картасының нинди өлешләрдән торуын, кайсы санның нәрсә аңлатуын белеп торсын. Банк картасы мәгълүматларын беркемгә дә, хәтта үзен банк хезмәткәре дип таныштырган кешегә дә әйтергә ярамавын кат-кат искәртегез.

2. Банк картасының пин-кодын кәгазьгә язып куярга ярамый. Аны фәкать истә генә калдырырга кирәк.

3. Бала шикле сайтларга банк картасы саннарын кертергә ярамавын да белеп торсын. Сәүдә йортлары кебек җәмәгать урыннарында бушлай вай-файга тоташканда, карта номерларын сорасалар да, шикләнергә кирәк икәнлеген аңлатыгыз.

4. Балалар өчен чыгарылган банк карталарында көн дәвамында билгеле бер сумма кадәр генә акча тотарга рөхсәт иткән чикләү куеп була. Карта алуга, шул функцияне кушып куйсагыз, җаныгыз тыныч булыр.

5. Бала картасын югалтырга яки өйдә онытып калдырырга мөмкин. Шуңа күрә ул һәрчак кул астында торсын өчен, баланың банк картасын онлайн рәвештә өйдәге берәр гаджетка тоташтырып куйсагыз да артык булмас.

«Татар-информ»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Болары республика дәрәҗәсендә рәсми рәвештә оештырылса, тагын меңләгән кеше үзе белеп һәм аңлап, кайгырып һәм кабат мондый вакыйгалар булмасын дип, теракт корбаннарын искә алырга җыелды. Һәлак булганнар рухына дога кылдылар, чәчәкләр куйдылар, яралаучыларга сәламәтлек теләделәр. Мондый чаралар Казан һәм Чаллыда гына түгел, кечерәк шәһәрләр, хәтта бистәләрдә узды.

Үрнәк күрсәтүчеләр

Нинди генә ысул кулланылса да, терактларның максаты бер – халыкны куркыту, шул рәвешле ыгы-зыгы китереп чыгару. Куркыныч булдымы, әйе, куркыныч булды. Әмма шунда ук башкалар өчен үз гомерен кызганмаган кешеләр табылды. Икенче көнне Мәскәүдә кан тапшыручылардан берничә чакрымга сузылган чиратлар тезелде. Һәлак булган һәм яраланган кешеләрнең гаиләләренә ярдәм кулы сузучылар башкаларга үрнәк күрсәтте. Куркырга түгел, ә бергә булырга өйрәттеләр. «Крокус Сити Холл»да берничә дистә кешегә котылу юлы күрсәткән 15 яшьлек үзбәк егете Ислам Хәлилов исә батырлыгы белән башкаларга сабак та бирде: террорчының милләте дә, дине дә булмый!

Әмма куркытырга теләүчеләр дә күп. Заманасы шундый: шул ук социаль челтәрләрдә ялган хәбәрләр тарала. Коткы таратучылар һәм фаҗигадән файдаланып калырга теләүчеләр җитәрлек икәнен күреп торабыз. Мондый вакыйгалар кемнең кем икәнен ачып сала. Санкт-Петербургта һәлак булучылар истәлегенә куелган урыннан чәчәк урларга маташучы ханым кебекләр турында бармый сүз. Куркынычраклары бар. Хокук сакчыларына терактны оештыручыларга кемнәр ярдәм иткәнен дә ачыкларга туры киләчәк. Шул исәптән, үзебезнең яктан да.

Җиде кат үлчәп

Канлы вакыйгадан соң катгый чаралар күреләсе көн кебек ачык. Алар, әлбәттә, булачак, тәкъдимнәр дә җитәрлек. Иминлек мәсьәләсендә таләпләрне көчәйтү турында күп сөйлиләр. Гаҗәп түгел. Миграция юнәлешендә тәртип салырга, килеп-китүчеләрне яхшырак тикшерергә кирәк, диләр. Монысы да аңлашыла. Бу көннәрдә үлем җәзасын кире кайтару турындагы сүзләр дә еш яңгырый. Россиядә мондый җәза бирүгә карата мораторий 1997 елда гамәлгә керде. Аңлатып үтәбез: җинаяте дәлилләнгән кешегә андый хөкем карарын хәзер дә чыгарырга мөмкиннәр, әмма аны гамәлгә ашырып булмый. Канунны үзгәртергә, үлем җәзасын кире кайтарырга тәкъдим итүчеләр арасында исемнәре билгеле һәм сүзе үтә торган кешеләр дә бар. Алар фикеренчә, мондый җәза гамәлдә булса, куркыныч җинаятькә баручылар саны кимер иде. Төрле вакытта оештырылган сораштырулар халык арасында да моның белән килешүчеләр аз түгеллеген күрсәтә. Каршы чыгучылар да бар. Алары әйтүенчә, кешелектән чыккан кешеләргә җәзаның иң катысын бирү бу очракта җәзадан котылуның иң җиңел юлы булачак.

«Россия – Ислам дөньясы» Стратегик күзаллау төркеме Мәскәү янындагы «Крокус Сити Холл» үзәгендә 137 кешенең гомерен өзүгә китергән террорчылык актын кискен төстә гаепләде. Оешманың белдерүен аның рәисе, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов хуплады.

«Мәскәү янындагы «Крокус Сити Холл» концерт залында булган котчыкмалы террорчылык актына бик нык тетрәндек һәм аны катгый төстә гаеплибез. Һәлак булганнарның якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз, зыян күрүчеләрнең тизрәк савыгуларын телибез. Коточкыч вәхшилектә гаеплеләрнең барчасының да лаеклы һәм җитди җәза алачагына ышанабыз», – диелгән белдерүдә.

«Россия – Ислам дөньясы» Стратегик күзаллау төркеме белдерүендә әйтелгәнчә, террорчылык, нинди генә рәвештә булмасын, дөньяга, иминлеккә иң җитди янауларның берсе булып тора. Ул бүгенге чорның иң куркыныч проблемасына әйләнде.

«Террорчылар, милләт һәм дин артына яшеренеп, үз максатларына ирешү өчен кан кою ысулларын куллана, халыкта курку хисе таратырга һәм тотрыксызлык булдырырга тырыша. Милләтара тынгысызлыкка юнәлдерелгән коткыга бирешергә, милли яки дини билгеләр буенча аеруга юл куярга ярамый. Җир шарындагы барлык сәламәт акыллы кешеләр, шул исәптән, мөселманнарны кертеп, барлык диннәр вәкилләре, әлеге канкойгыч терактны гаепләде. Безнең көчебез – бердәмлектә», – диелгән белдерүдә.

Оешма, террорчылыкның җимергеч идеологиясенә каршы алга таба уртак рәвештә көрәшүнең мөһимлеген искәртеп, халыкара террорчылыкка каршы юнәлдерелгән өстәмә чаралар эшләргә чакыра.

ЯНӘШӘ ТОРУ ДА ҖИТӘ

Сәламәтлек

Җитез, чыдам һәм мәкерле... Туберкулезны табиблар берничә сүз белән әнә шулай тасвирлый. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, Җир шарында ел саен 10 миллионлап кеше туберкулез йоктыра. Шуларның 1 миллионы – балалар. Туберкулез планетада үлем-китемгә китергән иң төп ун авыру рәтендә кала бирә.

Узган ел Татарстанда 881 кешегә туберкулез диагнозы куелган. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, 9,5 процентка азрак. Шул рәвешле узган ел республикада 100 мең кешегә 22 туберкулез йоктыру очрагы туры килгән. Идел буе федераль округындагы саннардан 23 процентка азрак. Бу хакта Бөтендөнья туберкулезга каршы көрәш көне алдыннан уздырылган матбугат очрашуында Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы урынбасары Анна Алешина җиткерде.

Аның сүзләренә караганда, Спас, Яңа Чишмә һәм Югары Ослан районнарында туберкулез йоктыручылар саны республика күләмендәге уртача саннан 2,5 (!) тапкыр күбрәк. Белгечләр яшерми: борынгы чирнең әле дә булса ныклап тамыр җәюенә алар үзләре дә шакката. Республика туберкулезга каршы көрәш диспансерының баш табиб урынбасары Наилә Газизуллина сүзләренә караганда, Мисырда табылган кеше сөякләрендә үк туберкулез эзләре ачыкланган булган.

– Туберкулез үлем-китемгә китергән авырулар исемлегендә коронавирустан соң икенче урында тора. Тормышыбызда ковид пәйда булмаган булса, туберкулез элеккечә үк кеше гомерләрен иң күп кырган мәкерле чир булып калыр иде, – ди табиб.

Мәкерле чир балаларны да аямый. Узган ел республикада аны 14 яше тулмаган 23 бала, 15–18 яшьлек 4 үсмер йоктырган. Бу, узган ел белән чагыштырганда, 18 процентка азрак.

– Кечерәк балаларда туберкулез бернинди билгеләрсез уза. Үсмерләр исә хәлсезлектән интегә, тиз арый, температурасы күтәрелә. Форсаттан файдаланып, баласын тикшертүгә каршы булган ата-аналарга мөрәҗәгать итәсем килә. Манту яки диаскинтест – балада туберкулез барлыгын-юклыгын ачыкларга ярдәм итүче бердәнбер ысул. Уңай нәтиҗә бирсә, ата-ана баласының сәламәтлегенә тагын да игътибарлырак булырга, аны бер ай дәвамында фтизиатрга күрсәтеп торырга тиеш. Мондый тикшеренү узмаган бала белем бирү оешмасына кертелми, – ди Анна Алешина.


freepik.com

Республика туберкулезга каршы көрәш диспансеры баш табибының балалар сәламәтлеге буенча урынбасары Рәмзия Фатыйхова сүзләренчә, республикада ел саен өч меңләп бала туберкулез йоктыру куркынычы янаган кешеләр исемлегенә кертелә.

– Бу балалар гадәти тормыш алып бара. Әмма алар шул ук вакытта табиб язган профилактик дәвалау курсын да узарга тиеш була. Балалар туберкулезны, гадәттә, өлкәннәрдән йоктыра. Шул рәвешле вакытында флюорография узмыйча, үз сәламәтлегенә салкын караган өлкән кеше ныгырга өлгермәгән бала организмы өчен дә куркыныч тудыра, – ди табиб.

Билгеле булганча, туберкулез – үпкәләрне зарарлаучы йогышлы чир. Ул авыру кеше йөткергәндә, төчкергәндә һава аша күчә. Туберкулез белән авырган кеше ел дәвамында 10–15 кешегә чир йоктырырга мөмкин. Шуңа күрә чирне вакытында ачыкларга кирәк, дип кисәтә табиблар. Өстәвенә ул бик чыдам. Әйтик, авыру кешенең тирәсендәге бактерияләр кипкәннән соң да ун ай дәвамында, ә караңгыда өч елга кадәр саклана. Алар авыруның киемендә, көндәлек кирәк-яраклары, китапларда да бик озак тора.

Белгечләр җиткергән саннардан аңлашылганча, бүген туберкулездан дәвалану курсы уртача 10 мең сумга төшә. Әмма соңгы елларда бу чирнең моңа кадәр кулланылган дәвалау ысулларына бирешми торган төрләре дә пәйда булган. Аларын дәвалау тагын да кыйммәткә төшә. Шуңа күрә чирне ничек тә булса алдан кисәтергә кирәк, ди табиблар.

Сүз уңаеннан, Бөтендөнья туберкулезга каршы көрәш көне якынлашканда Бөекбританиядә чирнең яңа штаммы ачыкланганлыгы билгеле булды. Белгечләр фикеренчә, ул тиз арада бөтен Европага таралырга мөмкин. Туберкулезның яңа штаммы моңа кадәр билгеле булган төрләреннән күпкә куркынычрак, аннан үлүчеләр саны да күбрәк булачак, дип фаразлый алар. Хәзерге вакытта туберкулезның яңа штаммын Бөекбританиядә яшәүчеләрнең дүрттән бере йоктырган инде. «Ул сулыш аша тарала. Туберкулезның яңа штаммы авыру кеше янында басып торсаң да, йога. Ул бернинди симптомнарсыз гына уза. Моңа кадәр әлеге чир ютәлләгәндә йога дип санала иде», – дип кисәтә эпидемиологлар.

Россия табиблары исә, безгә бу куркыныч янамый, дип тынычландыра. Үзәк фәнни тикшеренү институты җитәкчесе урынбасары Оксана Комиссарова «Парламентская газета» басмасына биргән интервьюда шулай дип белдергән.

– Күп кенә илләрдә, шул исәптән Бөекбританиядә туберкулезны алдан кисәтү системасы көйләнеп бетмәгән. Шуңа күрә алар яңа штаммга тизрәк бирешә дә. Россиядә исә бу эш җентекле рәвештә алып барыла. Шуңа күрә туберкулезның яңа штаммы безгә куркыныч тудырмый, – дигән ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Туберкулез турында 3 сорау

:: Чирдән ахыргача дәвалап бетереп буламы?
– Туберкулездан ахыргача дәвалап бетереп булмый. Бу инфекция әнә шул ягы белән куркыныч та. Кеше ничек кенә ныгытып дәваланмасын, әлеге инфекция аның организмында гомерлеккә калачак.

:: Дәвалану күпмегә сузыла?
– Дәвалану өчен ким дигәндә ярты ел вакыт кирәк. Аның җитдирәк төрләре вакытында ел ярым – ике елга кадәр үк сузылырга мөмкин.

:: Дәвалануны ярты юлда өзсәң, ни була?
– Туберкулездан дәвалануны ярты юлда калдырсаң, чир яңадан әйләнеп кайтачак. Ул гына да түгел, чир тагын да азып, моңа кадәр эчелгән даруларга бирешми башлый. Аннан дәвалану да шулкадәр кыенрак булачак, озакка сузылачак.

Ел укытучысы – 2024

Үзгәрү

Татарстанның иң яхшы укытучысы Казанның 108 нче мәктәбендә белем бирә. 30 яшьлек физика укытучысы Радик Хәбиров «Россия ел укытучысы – 2024» конкурсының республика этабында җиңү яулады. Ул көзен Саратов өлкәсендә узачак бөтенроссия конкурсы финалында Татарстан данын яклаячак.

«Татар-информ»

Әлеге һөнәри конкурста ел саен республикада 800дән артык укытучы катнаша. Мәктәп, район, зона ярышларын узып, шуның 65е республика дәрәҗәсенә чыга. Төбәк этабы 18–22 мартта үтте.

Быел бәйгедә сыналучыларның иң яшенә – 23 яшь. Аларның уртача яше – 38.

Үз осталыгын күрсәтергә теләүчеләр өчен нинди генә номинацияләр юк. Әйтик, «Педагогик дебют» бәйгесендә иң көчлесе – башкаланың 122 нче мәктәп укытучысы Ксения Епишева. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында абсолют җиңүчеләр – Казанның 19 нчы гимназиясеннән Ләйлә Гарифҗанова һәм Мәскәүдәге 1186 нчы мәктәптән Альбина Вәлиева. «Иң яхшы авыл укытучысы» Ленар Хәбибуллин Чистай районының Мөслим урта мәктәбендә география укыта. Татарстанда «Ел тәрбиячесе» республика һөнәри конкурсында Дарья Ольденбург җиңүче булды. Ул Чаллының «Шаян» катнаш балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Алдагы язмаларда «иң-иң»нәр белән таныштыруыбызны дәвам иттерербез.

Кем ул – иң шәп укытучы? Хәтерләсәгез, Радик Хәбиров 2018 елда бер мәртәбә Татарстанның «Ел укытучысы» булып танылган иде инде. Быел тагын үзенең көчен сынарга булган. Шушы еллар эчендә аның берничә мәктәптә эшләп карарга өлгерүен дә беләбез. Арада сәләтле балалар укый торганы да, гади мәктәпләр дә бар. Моның сәбәбен ул тәҗрибәнең төрлесен туплап карау теләге белән аңлатты. Сүз уңаеннан, егет башта инженер-төзүчегә укыган. Тик бу һөнәрдә әллә ни канәгатьлек хисе кичермәгән. Аның һәрвакыт нәрсәдер төзисе килгән. Юк, биналар түгел икән, чын, тере әйберләр… Илнең киләчәген төзүдә катнашасы килә аның. Шуны аңлап, мәктәпкә укытырга килгән.

Ике бәйге арасында мәктәптә нинди яңалыклар булуын да сораштык. «Шушы еллар эчендә карашым үзгәрде. Шуңа күрә дә күп әйберләр үзгәргән кебек тоела», – диде ул.

– Мин һәрвакыт конкурсны аралашу өчен мәйданчык, педагогик үсеш, осталык мәктәбе дип уйлый идем. Әмма бу юлы бәйгенең үзгәрү өчен бер мөмкинлек булуына төшендем. Һәм без барыбыз да яхшы якка үзгәрдек, – диде Радик Хәбиров.

Педагог әйтүенчә, аңа ниндидер яңа үсеш, тәҗрибә, саф һава йотымы кирәк булган. Шуңа күрә быел бәйгедә тагын бер кат осталыгын сынап караган. «Хезмәттәшләремнең дә, методистларның да ярдәме зур булды. Гаиләм дә ышанып, көч биреп торды. Бер генә кеше ерып чыга, җиңел генә бирелә торган бәйге түгел бу. Сынаулары да, авыр вакытлары да, йокысыз төннәре дә күп. Укучыларым көн саен: «Кайчан кайтасыз инде?» – дип язып, хәлләремне белешеп торды, – ди Радик Хәбиров.

«Буыннар алмашынса да, балалар үзгәрде, димәс идем». Монысы да – Радик сүзе. Һәрберсенең күңеленә ачкыч табарга тырыша ул.

– Дәресне кызыклы итеп үткәрсәң, фәнне дә яраталар. Теорияне генә түгел, белемне тормышка яраклаштырып бирәм. Төрле мисаллар китереп аңлатам. Мәктәпне тәмамлагач, алар физика буенча формулаларның кайберләрен онытырга мөмкин, әмма көнкүрешкә бәйләп аңлатканнары исләреннән чыкмас дип ышанам, – диде «Ел укытучысы».

Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин «Ел укытучысы»на пеликан сыны һәм сертификат тапшырды. «Педагогик дебют» бәйгесе җиңүчеләренә – 200 мең, башка номинацияләрдә иң яхшысы дип табылганнарга 400 мең сум акча бирелде. Шунысын да әйтергә кирәк: быел бәйгегә республиканың эре сәнәгать предприятиеләре дә үз өлешен керткән.

Сәрия МИФТАХОВА

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

tatarstan.ru

КЕРСӘҢ, ЧЫГАРМЫН ДИМӘ...

Урман хуҗалыгы

Яз башында Халыкара урман көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан Татарстан урманчылары эшләгән эшләренә йомгак ясап, озак еллар эшләгән ветераннарын искә алып, проблемаларын уртага салып сөйләштеләр.

Урманда эшләр зарланырлык түгел. Техникалары җитә, үстергән кәлшәләре артып та кала әле. Янгынга да әзер торалар. Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, бер генә зарлары бар: урманчыларның хезмәт хакы аз. Инде хәбәр иткәнебезчә, яшьләрне урманга тартуның төрле юлларын эзлиләр. Республикада Лубян урман-техник көллиятен тәмамлап эшкә килүчеләргә – бер тапкыр 150 мең, югары уку йортын бетерүчеләргә 300 мең сум ярдәм бирелә.

– Урман утырту, агачларны янгыннан саклау буенча бернинди проблемалар да юк, – ди ул. – Әмма урманчыларның хезмәт хакын күтәрәсе иде. Россия Президенты Владимир Путин үзенең Юлламасында бу хакта әйтте. Урманчыларның хезмәт хакын күтәрергә кирәк, диде. Бу хәбәргә бик шатландык. Чөнки хезмәт хакы аз булу кадрлар кытлыгына китерә.

Биредә урманчыларның эшен күрсәткән күргәзмә дә эшли. Соңгы елларда бу өлкәдә барлыкка килгән яңа технологияләрне дә күреп була. Яшел Үзән урманчылыгы җитәкчесе Наил Абдуллин исә килгән кунакларга урманга чүп ташлаучыларны эләктереп ала торган камера турында сөйләде.

Күргәзмәне караган министр да урманчыларның эшенә югары бәя бирде. Заманнан калышмыйбыз, диде ул.

– Мондый бәйрәмнәр кирәк. Кешенең колагына керә, яшьләр ишетә. Без урманнарны бергәләп сакларга тиеш. «Урманнарны саклау» федераль проекты ярдәмендә без шактый эшләр башкардык. Республикада авыл хуҗалыгы җирләрендә, машина юллары янында, елга-күлләр янәшәсендә агачлар утыртылды. Аларның гомуми мәйданы 145 мең гектарны тәшкил итә. Шуларны исәпләп Татарстанда урман мәйданнары 20 процентка җитте. «Экология» илкүләм проекты ярдәме белән цифрлаштыру эшләре дә башкарыла. Урманнарны янгыннан саклау өчен бар кирәк-ярак алынды. Кискән агачлар урынына яңаларын утыртабыз. Урман яңарту буенча без Россиядә беренчелекне алып торабыз, – ди министр. – Татарстанда урман җирләре 1,2 миллион гектарны тәшкил итә. Агачларның үсүе төрле җирдә төрлечә. Әйтик, Чүпрәледә ул – 2,9 процент, Нурлатта 41,3 процентны тәшкил итә.

Бу көнне урман тармагында озак еллар эшләгән ТАССРның атказанган урманчысы Әхмәдулла Газизуллин истәлегенә Татарстанның авыл хуҗалыгы университетында мемориаль такта ачылды. Тантанада катнашкан Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов урманчы турында хатирәләрен яңартты.

– Әхмәдулла Газизуллин – гомере буе урманда эшләгәч, анда нинди проблемалар барын белгән кеше. Урман туфрагын да, агачларны дөрес итеп кисү алымын да өйрәнгән ул. Әтием белән бергә эшләде алар. Төрле сортлы агачларны ничек утыртырга кирәклеген өйрәнгән кеше дә ул. Ул чакта миңа урман турында бары тик Әхмәдулла Газизуллин гына белә кебек тоела иде, – ди ул. – Әхмәдулла абый урманнарны үстерү буенча да күп көч куйды. Ул үз эшен исбатлап, фәнгә бәйләп бирә иде. Татарстан урманнарының бүгенгесе – аның хезмәте.

Рифкать Миңнеханов та үзен урман баласы дип саный.

– Урманчылар бәйрәменә минем дә катнашым бар. Әтием Нургали урманчы булгач, гаиләбезгә урман темасы якын иде. Язмыш мине башка өлкәдән алып китте, – диде ул.

Саба районы башлыгы Рәис Миңнеханов та Әхмәдулла Һади улын җылы сүзләр белән искә алды.

– Барыбыз да аннан өйрәндек. Туфракны өйрәнү буенча беренчелекне бирмәде ул. Советлар Союзында да, Россиядә дә, Татарстанда да ул баш туфракчы иде. Үзенә алмашлар әзерләп, урман хуҗалыгын белгечләргә баетып калдырды, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

Татарстанда агачларның **16,7** проценты – каты яфраклы, **61,3** проценты – йомшак яфраклы. Безнең урманнарның **20,6** процентын – усак, **19,7** процентын – юкә, **17,6** процентын – каен, **15,6** процентын – нарат, **13,8** процентын – имән, **5,9** процентын чыршы били.

СОЛДАТ ӘНИСЕ

Ватан хакына

Әниләр генә шундый сабыр һәм киң күңелле була ала. Эче тулы ут булса да, тышка чыгармыйча, өметләнеп көтә ала. Аксубай районының Карасу авылында гомер итүче Венера Мәхмүтова да газизенең яу кырыннан исән-имин туган якларга әйләнеп кайтуын көтә.

Рифат Мәхмүтов Аксубай хастаханәсендә фельдшер булып эшләгән җиреннән армиягә алына. Шуннан соң контракт төзергә, Югары хәрби академиягә укырга керергә карар кыла.

– 2022 елның февралендә контракт төзеп, Югары хәрби академиягә документларын тапшырды. Ул вакытларда дөньялар тыныч, күкләр аяз иде бит әле. Апрель башында уку йортына керер өчен имтихан тапшырырга барырга тиеш иде. 14 февральдә улым: «Әни, безне Курскига командировкага алып китәләр. Элемтәгә чыга алмасам, борчылма», – дип шалтыратты. 22се кабат элемтәгә чыгып, әйберләрен, шул исәптән телефоннарын тапшыруларын да хәбәр итте, – диде Венера апа.

Бераздан ул эшнең нидә икәненә төшенә. Көне телевизордагы яңалыкларны, хәбәрләрне карап башлана һәм тәмамлана. Шул шалтыратудан соң газаплы унҗиде көн уза. Баласыннан хәбәр көткән ананың йокысы кача, тамагыннан ризык үтми. Зарыгып көткән хәбәрне исә 7 мартта гына ала.

– Безнең балалар яу кырына иң беренчеләрдән булып барып кергән булып чыкты. 7 март көнне нинди дер билгесез номердан шалтыраттылар. «Әни, бу мин», – диюгә елап та җибәрдем. Анысында берничә сүз генә әйтә алды, ләкин миңа алары да алтынга тиң сүзләр иде. 8 мартта үз телефоныннан элемтәгә чыгып, авыр зонадан чыгуын җиткерде, – ди Венера апа.

Ул елны ялы Сабантуй көннәренә туры килә. Шунда көрәшеп, Сабантуй батыры да булып кала әле Рифат.

– Ялга биш тапкыр кайтып китте инде улым. Ии, каршы алулар рәхәт инде, озатулары гына яман. Ул бусагадан атлап кергән көннәр – бәйрәм. Барыбыз бергә җыелышып кочаклашабыз, сөйләшеп туя алмыйбыз. Рифатның бервакытта да зарланганы юк. «Әни, минем барысы да яхшы, син борчылма», – дип кенә тора, – ди ул.

Андый вакытларда догалар, Аллаһы Тәгаләгә ышану, сабырлык коткара Венера апаны. Улы сугышка эләккәч, намазга да баскан, шушы көннәрдә хаҗга барырга ниятләп тора икән.

– Улымны да шул догаларым саклап йөртәдер, дим. Үзе дә кайткан саен догалар язып алып китә. «Аларны укыгач, рәхәт, тыныч булып китә», – ди. Беренче вакытларда бик авыр булды, саулыгым да какшады. Тәнем белән бергә җаным да бәргәләнде. Йөрәк түреннән улыма багышланган шигырьләр туды. Хәзер барыбер азрак тынычландым шикелле. «Телеграм»га керүкермәвен карап кына торам. Иртә белән кергән булса, ул көнне мин очып йөрим, бөтен эшләрне җиңеллек белән эшләп куям. Югалып торса, хәбәре булмаса, үлеп терелэм инде. Солдат әнисенең күңел халәтен баласын сугыштан көткән кеше генә аңлыйдыр, дип уйлыйм, – ди Венера апа.

Олы улы Фаил шулай ук элеккеге хәрби, бүген гаиләсе белән Санкт-Петербургта яши. Бер кызлары – Казанда, төпчекләре Түбән Камада «ТАИФ»та эшли. Оныгы Каринаны да үзе тәрбияләп үстергән Венера апа.

– Мин мәктәптә пешекче булып эшләдем. Хәзер дә тик торганым юк. Фронттагы солдатларга гуманитар ярдәм дә әзерләп җибәрәбез, – ди ул.

Карасу авылыннан Украинага алты егет киткән. Кызганыч, берсе һәлак булган, берсенең әлегә хәбәре килми тора икән. Рифат Мәхмүтов исә әлеге көндә хирург булып эшли, яралыларга беренче ярдәм күрсәтә.

– Улым бик күп егетләрнең гомерен саклап калды, дип беләм. Савыгып, хастаханәдән чыккан берничә солдатның үземә дә рәхмәт әйтеп шалтыратканнары булды. Ул чакларда күңел бигрәк тә нык тулып китә, – ди Венера апа.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ӨЙРӘНГӘНЕҢ – ҮЗЕҢӘ

Актуаль мәсьәлә

Көндез – укытучы, кич – бухгалтер. Илдә яшәүчеләрнең 42 процентының өстәмә керем чыганагы бар. Халык арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре әнә шуны күрсәткән. Атнасына берничә сәгать кенә эшләп, кайсы тармакта күбрәк түлиләр икәнен дә әйткәннәр. Эш белү яхшымы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауга ачыклык кертергә тырышты.

Кукмарада яшәүче Гөлнара Җәмалетдинова сак оешмасында эшли. Бушаган арада ясалма ротангтан (үрү өчен агач ботагына охшатып ясалган махсус синтетик материал. – **Ред.**) кәрзиннәр, кашполар үрә ул.

– Бу эшкә күптән кызыга идем, – ди кул остасы. – Бүген ротангтан үрелгән кул эшләнмәләренә ихтыяҗ зур. Әлеге материал дымга, салкынга, кояшка чыдам. Төсе дә уңмый. Әлегә күпчелек кашполар үрәм. Кәрзиннәргә дә заказлар бар. Бу эшкә Кама Аланында яшәүче остага барып өйрәндем. Беренче кашпоны өч сәгать ярымда үрдем. «Бик тиз эшлисең, гадәттә, мондый савытны биш-алты сәгать үрәләр», – дип тә мактадылар әле мине ул вакытта. Хәзер сәгатькә карап торган юк. Ротангны интернеттан да, арадашчылардан да сатып алырга мөмкин. Бернинди кытлык юк. 12 литрлы бер кашпога, мәсәлән, 600 грамм ротанг китә. Мондый савытның бәясе – 1300 сум. Кәрзиннәрне төрлечә үрергә мөмкин. Бу фантазия һәм осталыктан гына тора. Ә соңгысына эшли-эшли өйрәнәсең, әлбәттә. Үземә бик кызык. Үрү күңелгә рәхәтлек бирә, кул гел шул эшкә үрелә. Матур да бит. Элек тә тал чыбыгыннан үргәннәр. Ясалма ротанг исә чыдамлырак. Киләчәктә йорт җиһазлары да үрергә өйрәнәсем килә. Тик аңа кадәр ерак әле. Кулны шомартырга кирәк.

«Авито Работа» сервисы үткәргән сораштырудан күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 42 процентының өстәмә керем чыганагы бар. Респондентларның 25 проценты гына: «Ике кулыма – бер эш», – дип җавап биргән. Төп хезмәт урыныннан тыш, өстәмә эш эзләүчеләр хатын-кызлар һәм яшьләр арасында күбрәк. Сораштыруда катнашкан ике кешенең берсе былтыр бер тапкыр булса да өстәмә керем алуын әйткән. Ир-атлар рәсми рәвештә урнашмыйча гына төзелеш, IT һәм транспорт логистикасы кебек тармакларда күбрәк акча эшли икән. Хатын-кызлар пешерү, кул эшләнмәләре һәм сату өлкәсен атаган. Гомумән алганда, илдә яшәүчеләр өстәмә эшкә атнасына 5–9 сәгать вакыт сарыф итә икән.

Икътисад белгече Илдус Сафиуллин әйтүенчә, белгән һөнәр инсәне басмый.

– Беренчедән, тормыш шактый кыйммәтләнде. Кибеткә ипи-сөт сатып алырга керсәң дә, кимендә 1 мең сум акча туздырып чыгасың. Ә хезмәт хаклары бәяләрне куып тотарлык түгел. Икенчедән, пандемия чорында без, көтмәгәндә эшсез калсаң, өстәмә керем чыганагы кирәк икәнен яхшы аңладык. Эш белү файдага гына. Шуңа күрә хезмәт хакына, пенсиягә яки стипендиягә генә ябышып ятарга теләмәүчеләр артканнан-артачак, – ди белгеч.

Психолог Алинә Гәрәева исә чамасын белергә киңәш итә.

– Бүген җәмгыятьтә шундый караш бар: кеше күбрәк эшләгән саен уңышлырак булып санала. Атнасына җиде көн эшләп, ул арада театр, концертларга йөрергә өлгергән, спорт белән шөгыльләнгән, балалары «дүртле»-«бишле»гә генә укыган таныш-белешләребез турында сокланып сөйлибез бит. Тик һәр нәрсәнең чиге булырга тиеш. Эш белән артык мавыгып китеп, үзегезгә, гаиләгезгә буш вакыт калдырырга онытмагыз, – ди психолог.

Ул арада илдә яшәүчеләр тормыштан канәгать булу өчен күпме акча җитмәвен дә әйткән. Баксаң, һәр биш кешенең берсенә хезмәт хакыннан тыш аена 20 мең сум акча кирәк икән. Иң еш яңгыраган җавап әнә шул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Күпме өстәмә керем аласыз?

Марат ХӘЙРУЛЛИН, студент (Казан):
– Азык-төлек һәм йорт кирәк-яракларын өйгә китереп бирүче онлайн кибеттә эшлим. Укудан бушаган арада сәпид педален әйләндерәм, кыскасы. Биредә тулы көн эшләүчеләр аена 70 мең сумга кадәр хезмәт хакы ала. Мин ярты көнгә булса да эшкә чыгарга тырышам. Беренче вакытта аяклар йөрмәскә әйләнә иде. Хәзер ияләштем инде. Кирәк җиргә бик тиз барып җитәм. Өстәмә эштән аена 20–25 мең сум акча керә.

Лилия ВАФИНА, укытучы (Биектау):
– Һөнәрем буенча, мин – математика укытучысы. Балаларга белем бирәм. Акчаның җитәсе юк, әлбәттә. Шуңа күрә декрет ялында утырганда мәшгульлек үзәге аша бухгалтерлык белгечлегенә укыдым, «1С» программасын өйрәндем. Хәзер бер оешманың исәп-хисабын алып барам. Кич яки ялларда эшлим. Математика укытучысы булгач, саннар дөньясы яхшы таныш. Аена 15 мең сум өстәмә акча алам.

Әдилә ГАРИПОВА, банк хезмәткәре (Яшел Үзән):
– Биш елдан артык өйдә тортлар пешерәм. Рәсми эш урыным, пенсиягә чыккач, айлык түләү булсын өчен генә. Хезмәт хакына караганда, торт пешереп, күбрәк акча эшлим. Хәзер кечкенә бенто-тортлар бик күп сорыйлар. Андыйларны пешерергә дә уңайлырак. Авырлыгы ярты килодан да артмаган кечкенә татлы ризыкның бәясе 1200 сумнан башлана. Зур торт пешерсәң, бер килосы – 1 мең сум. Бәйрәм арасында унлап торт пешергән көннәр дә бар. Аена күп дигәндә 30–35 мең сумлык тәм-том сатам.

Рәхмәт ишетү рәхәт

Язма табыштырды

«Ватаным Татарстан» газетасының 20 март санында «Аклык эзләп үткән гомер» дигән язма дөнья күрде. Ул 95 яшен тутыручы Ракига апа хакында иде. Әлеге язма элемтәләре өзелгән туганнарны табыштырган.

– Әлеге язманың герое – минем әбиемнең туганы. Ракига апа белән элемтәгә чыгарга ярдәм итсәгез иде, – дип мөрәҗәгать итте безгә Казанда яшәүче Ләлә ханым.

Шатлыклы хәбәрне Ракига апа гаиләсенә дә җиткердек. Күп тә үтми, Ракига апаның кызы Роза ханым шатлыгы белән бүлеште.

– Кем уйлаган бит газетага яздырып әнигә шундый бүләк ясарбыз дип! Әни турында язып, сез аңа көтелмәгән бүләк ясадыгыз. Шулай итеп әнинең әнисе ягыннан туганыбыз белән табыштык. Өченче буын туганнар булабыз икән. Хәзер инде көн дә хәл белешәбез. Күңелдә әйтеп бетермәслек рәхәт хисләр. Тиздән әнине Вәсилә апа белән очраштырырга җыенабыз. Безнең хакта язып, дөньяга чыгарган өчен бик зур рәхмәт сезгә! Эшегездә уңышлар насыйп булсын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ФӘЙРҮЗӘ МӘҖИТОВА: «СӘГАТЬЛӘП ТҮГЕЛ, ТӘҮЛЕКЛӘП ЭШЛИМ»

Гамьле әңгәмә

Кайбер телевизион журналистлар бер караштан яки елмаюдан тамашачыны җәлеп итә белә. Катлаулы темаларны да халыкка җиңел һәм аңлаешлы итеп җиткерү – зур сәләт. ТНВ каналында «Канун. Парламент. Җәмгыять» тапшыруын алып баручы тележурналист Фәйрүзә МӘҖИТОВА – шундыйларның берсе. Аның белән журналист хатын-кызның гаиләдә нинди булуы, сайлаган һөнәренең үзенчәлекләре турында сөйләштек.

Фәйрүзә Мәҗитованың шәхси архивыннан

:: Укырга кергәнче, журналист булу теләгеңә әти-әниең нинди фикердә иде?

– Каршы килмәделәр. Укырга кергәч шатландылар гына, чөнки бу минем хыялым иде.

:: Ә үзеңдә журналист һөнәрен сайлаганга үкенү хисе юкмы?

– Төрлечә була. Иртәдән кичкә кадәр өйгә кайтып керә алмыйча бар вакытым эштә узганда якыннарыма, гаиләмә вакыт бик аз кала, дип үкенәм. Чөнки мин – әни. Ә әниенең йөрәге газиз балалары янында. Мин әни булгач, деканыбыз Васыйл абый Гарифуллин: «Фәйрүзә, эшне ташлама!» – дигән иде. Әни булган кешенең балалары янында калу теләгән җиңеп, телевизион журналистикадан китү ихтималын кузаллап әйтелгән сүзләр булган икән бу. Ә икенче яктан, мин эшемнән канәгать. Журналистика ул – рухи азык бирә торган хезмәт. Көн саен яңып-көеп, репортажны эфирга әзерләп бирү, канәгатьлек хисе аласың. Ул газетада да шулай, язмаң басылып чыккач, күңелгә ничек рәхәт бит! Бу өлкә кешеләре әнә шул адреналин белән яши.

:: Укыган чакта җитди журналистикада эшләрмен дип уйлый идеңме?

– Миңа иң мөһиме телевидениедә эшләү иде. Сәясәтме, мәдәниятме – барыбер. Ә ТНВга эшкә килгәч, миңа «Канун. Парламент. Җәмгыять» тапшыруын бирделәр. Сәясәт темалары шуннан башланды. Аннан соң «Безнең Республика – Безнең Гамәл» тапшыруын тәкъдим иттеләр. Монда да сәясәт дәвам итә…

:: Телевидениедә эшләүнең иң авыры нәрсә?

– Исән калу дияр идем. Телевидение (аеруча яңалыклар хезмәте) журналисты ул матур да, җитез дә, бер көндә өч районга барып кайтып, кич сюжетын эфирга өлгертүче дә, аннары кич театрга премьера тәшерергә чыгып китүче дә. Мәгълүмат ташкыны, бик күп кеше белән аралашу ардыра, әлбәттә.

:: Эштәгеләр арасында кушаматың бармы?

– Еш кына репортаж әзерләгәндә камера каршына баскач, мин әле ни сөйләргә икәнен үзем дә белмим. Ә бит тиз генә уйлап яздырырга кирәк. Оператор көтә инде. Үзем уйлыйм, үзем аларга «хәзер-хәзер» дим, шулай итеп аларны тынычландырам. Бер елны 8 Март бәйрәменә егетләр безгә календарь ясатты, фотобыз һәм каналты сүзләребезне язганнар. Минем фото янына «хәзер-хәзер» дип язылган иде.

:: Көненә ничә сәгать эшлисең син?

– Менә тугызга эшкә килгән идем, кичке унберенче яртыларда командировкадан әйләнеп кайтырбыз, дип торабыз. Сәгатьләп эшләмим мин, тәүлекләп.

:: Ялгызың гына калырга теләгән вакытларда нишләргә яратасың?

– Йокларга.

:: Китаплар укыйсыңмы?

– Китапханәгә йөрим. Татарча китаплар алам. Кайчак укымыйча гына илтеп бирәм. Ә укый башласам, кызык әсәр булса, ничек тә укырга җай табам. Ә өстәл китабым – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Кеше китә – җыры кала» әсәре.

:: Яраткан ризыгың нинди?

– Мин барлык ризыкны да яратам. Әни пешергәннәрен аеруча. Бигрәк тә бәлешне!

:: Тәмле ашлар пешереп, гаиләңә игътибар биреп яшәргә вакытың каламы?

– Вакытым калмаса да, пешерәм. Иртән эшкә китәргә ике сәгать алдан торам. Өйдә ризык булырга тиеш. Өй эшләрен бик тиз эшләргә өйрәндем. Репортажны эфирга өлгертсәм кебек, өчпочмакны да ярты сәгатьтә ясап, мичкә тыгып була.

:: Тормыш иптәшең һөнәреңне аңлыймы соң?

– Әгәр аңламаса, эшләп булмас иде. Бу яктан бездә тәртип, шөкер!

:: Нинди әни син? Кырысмы, таләпчәнме,ә бәлки?..

– Кырыс та, таләпчән дә, юаш та. Балалар эш җаен белеп үссеннәр дип, өй эшләрен өйрәтәм. Дәресләрен тикшерәм. Электрон көндәлекне атнага бер генә кереп карыйм. «Мин сезнең бәхетле булуыгызны телим!» – дип әйтәм үзләренә. Сөйләшергә тырышам! Алар күреп, аңлап үсә.

Әңгәмәдәш – Гөлназ ӘХМӘДИЕВА

Милләттәшләр

ТАМЫРСЫЗ АГАЧ БУЛАСЫ КИЛМИ

Быел җәй милләттәшләребез Мари Эл Республикасы башкаласы Йошкар-Олага җыела. Россия күләмендә үткәреләчәк Сабан туе нәкъ менә шунда тәгаенләнде.

Зур җыенны оештырып, күпсанлы кунакларны кабул итәргә әзерләнгән төбәктә татарлар ничек яши? Милләттәшләребезнең тормыш-көнкүреше, тырышып-тырмашып көн итүләре хакында без шактый язган идек инде. Бу юлы Татарстанның атказанган мәдәнияте хезмәткәре, 35 ел гомерен шушы өлкәгә багышлап, 30 ел буена Мари Эл телевидениесендә татар тапшырулары оештырырга һәм алып барырга да өлгергән, республикадагы татар авылларының тарихын барлаган Мәүлизә Гомәрова белән күбрәк проблемаларга кагылып үтәргә булдык.

Мәдәният

– Мәдәният йортларының күбесе иске, агачтан эшләнгән. Авария хәлендә булганнары да бар. Шуңа да карамастан, мәдәният хезмәткәрләре, эшләрен намус белән башкарып, милләтебезнең гореф-гадәтләрен килачәк буынга тапшыралар. Бу җәһәттән бигрәк тә Морки районы Кымыгырҗа авылында эшләүче Айсылу һәм Динарт Хәмидуллиннарны атап китәр идем. 50 еллык тарихы, ярым җимерек хәлдә булган агач мәдәният йортында, 1993 елда республикада беренчеләрдән булып халык ансамбле исемен яулаган төркем эшләп килә. Алар шулай ук беренчеләрдән булып Авыл, Шәжәрә бәйрәмнәре уздырдылар. Сугышта хәбәрсез югалган, һәлак булган 85 кешегә авыл халкы, эшмәкәрләр ярдәме белән истәлек тактасы куйдылар. Татар авыллары арасында беренчеләрдән булып авыл тарихы турында язылган китаплары дөнья күрде.

Республика, җирле хакимият, татарларның мәнфәгатен яклап, Мари-Төрек, Бәрәңге, Морки районнарында авария хәлендә булган мәдәният йортларына матди ярдәм күрсәтеп төзекләндерсен иде дигән теләк бар. Килачәктә мәдәният йортларыбыз милли киемнәр, уен кораллары белән тулыйсын иде. Республика күләмендә татар телендә чыга торган берданбер «Якташлар» газетасының баш мөхәррире, иганәчеләр эзләп, үз акчасын тотып интегә. Матди ярдәм күрсәтелеп, татарларны берләштерә торган басмага әверелсен иде бу газета.

Мари дәүләт телерадиокомпаниясендә «Туган тел» тапшыруы өчен элекке елларда эфирда 30 минут вакыт бирелде. Хәзер ул 11 минутка гына калды. Эфир вакыты арттырылсын иде. Радиодан исә татар телендә тапшырулар бөтенләй яңгырамый.

> **Сан**
> Бәрәңге районында **11** татар авылына – **6**, Мари-Төрек районында **18** авылга – **5**, Морки районында **3** авылга **3** мәдәният йорты бар.

Битарафлык

Бер караганда үзебез дә гаепле инде. Республикада катнаш никахлар чәчәк ата. Татар эреп югала дигән сүз бит бу. Элегрәк дәүләт, шәһәр собраниеләренә берничә татар депутаты эшләп килсә, бүген, ни кызганыч, милләттәшләребез проблемасын хәл итәргә алынучы бер генә депутатыбыз да юк. Без ятим балалар кебек. Республикадагы татар дөньясы яшь кадрлар ягыннан да мохтаҗ. Яшьләр укырга киталәр һәм әйләнеп кайтмыйлар. Чөнки җитәкчеләр тарафыннан аларга йөз белән борылу юк. Кирәксенмиләр. Мәгариф өлкәсендә йөрәкне әрнетеп торган проблемалар аеруча күп. 11 меңгә якын татар яшәгән Йошкар-Ола шәһәрендәге мәктәпләрдә бер генә татар сыйныфы да, балалар бакчаларында бер генә татар төркеме дә юк. Саф татар авылларында да белем алу рус теленә күчеп бетте. Атнага бер-ике татар теле дәресе белән генә әллә ни майтарып булмый инде.

> **Сан**
> Республикада **30** мәчет эшли, **19** мәктәптә татар теле һәм әдәбияты дәресләре укытыла.

Тарих

Сүз дә юк, бүген алдыбызда торган иң зур проблемаларның берсе – татар авыллары саклап калу, милләтебезнең бөек шәхесләрен өйрәнү. Яшерен-батырын түгел, татар авылларының саны Россия күләмендә зур тизлек белән кими. Аңлашыла инде: күп кенә авылларга асфальт юллар салынмаган, су кермәгән, утын әзерләп, мич ягалар… Ләкин төп сәбәбе ул түгел. Бигрәк тә эш булмау яшьләрне читкә китәргә мәҗбүр итә. Бу җәһәттән: «Эш булса, бүген үк авылга кайтыр идек», – дигән сүзләрне дә еш ишетергә туры килә.

15 елдан артык гомеремне Мари Эл Республикасындагы татар авылларының тарихын өйрәнүгә багышладым. Архив материалларына таянып, һәр авыл турында тапшырулар тәшердек. Ни кызганыч, республикада 18 татар авылы юкка чыккан. Кайберләре урынында – басу, урман эчендә калганнары да бар. Мари-Төрек, Бәрәңге районнарында берәр авылның зиратлары, урман эчендә калып, чүплеккә әйләнгән. Калган 16 авылның мәчетләре йортлары матур итеп киртә белән әйләндереп алынган. Шул авылда туып-үскән, хәзер башка җирдә яшәргә мәҗбүр булган авылдашлары карап, чистартып торалар. Эшлим дисәң, була инде ул. Бүген республикадагы 50 татар авылының тарихы Мари дәүләт телерадиокомпаниясендә саклана. Бу җәһәттән бигрәк тә тарихчы Наил Бариев белән «Яңарыш» газетасы мөхәррире Фәнил Мусинга рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Бөтен көчләрен куеп, эшләрен җиренә җиткереп эшлиләр. Алар ярдәме белән тарихчыларыбыз төрле архивлардан ярты миллион сумлык материаллар алып кайтты. Мәскәү, Киров, Казан, Уфа, Йошкар-Ола архивларыннан алып кайтасы документлар күп әле. Тырышабыз инде. Татарда «Тарихын белмәгән халык – тамырсыз агач» дигән әйтем бар бит. Ул халәгә каласы килми.

Иң зур теләгем шул: һәр кешенең туган җирендә үз өе, ул өй эчендә үз көе, үз моңы яшәсен иде. Бөтендөнья татар конгрессының ярдәмен һәрвакыт тоеп торабыз. Чиксез рәхмәтлебез. Без Татарстанның капка төбендә генә яшибез. Киеребрәк ачып куйсак, аралашырга да, ярдәмләшергә дә бернинди чикләр комачауламый. Шуңа күрә игътибар да күбрәк булыр, дип өметләнәбез.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

nbmariel.ru

> **Сан**
> Республикада Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган **53** кешенең **3се** – татар. Алар – Таһир Керҗнев, Әхмәтсафа Гайсин, Хәким Хәсәнов. Россия Геройлары – **5**, **1се** татар – Радик Бариев.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Җиңү – җиңелүнең соңлап килүе ул

Камиллеккә омтылыш кирәктер инде ул, ансыз булмый торгандыр. Тик менә Көнчыгыш фәлсәфәсе аны бер дә хупламый. Буддизмны алсаң да, даосизм да, башкасы да уртачалык яклы – инь белән янь тигезлеген саклауны алга сөрә.

Бу тәгълиматлар белән танышкач, тирә-ягында дулкыннар тудырудан куркып, сай суда утырган кешене күз алдына китергәнем хәтердә. Ләкин алай итеп яшәп булмый, сай су ул хәтта сулыш алудан да, кан тамырларын тибүеннән дә дулкынланып ала. Бу яклар фәлсәфәсе буенча адәм баласы берни дә кылмыйча, тигезлек саклап кына утырырга тиеш кебек килеп чыга. Сүзгә-сүз аңларга кирәкмәгән инде моны, Көнчыгыш бит ул тормышка шагыйранә карый.

Ислам динендә дә шуңа охшашрак төшенчә бар, әмма ул бу тиклем үк катгыйлыктан китә һәм инь белән янь тигезлеген беркадәр кинәйтеп, аны күңел тынычлыгы белән алыштыра. Монысы инде тулы азатлык кебек тоела, чөнки синә чиксез ирек бирә: теләсә нәрсә эшлә, әмма күңелең генә тыныч булсын. Күңелең тыныч булсын өчен үзеңне Ходай каршында да, бәндә алдында да гаепсез дип саный алу кирәк. Бу җиңел түгел, кемнедер ялгыш сүз әйтеп кенә үпкәләтсәң дә, күңелең тыныч булмый. Бурлык белән баеган, кан-яшь түктереп, адәм рәнҗетеп яшәгән кешеләр дә хәтсез бит инде, менә аларның бөтен нәрсәсе дә булырга мөмкин: чит илләрдә фәлән миллиард сум акчалары да, кыйммәтле яхталары да, виллалары да – бары тик күңел тынычлыгы гына була алмый. Тормышның берөзлексез эшли торган кырыс кануны бар: әгәр кемнендер тынычлыгын бозасың икән, үз тынычлыгыңны югалтасың. Күңел тынычлыгы ул бәхетнең үзе бугай инде, фани дөньяның җәннәт белән тигез урыны.

Буддизмны мин кызаллау өчен җиңел булганга гына телгә алдым. Чынында барлык диннәрдә дә бар мондый төшенчә. Мәҗүсиләр дә агачны еккач, җәнлекне аулап алгач, алардан гафу үтенә торган булганнар. Үз ихтыяҗларына кирәклесен алганнар да артыгына үрелмәгәннәр. Үзеңә җылы биргән нәрсәләргә, ризыкка хөрмәт әнә шул чордан ук калган. Ә христиан дине турыдан-туры кисәтә: үтермә, урлашма, алдашма, зина кылма… Әгәр шушы кануннарны бозасың икән, күңел тынычлыгы югала, инь – янь тигезлеге бозыла дигән сүз бит инде бу. Йолалары, тәләре төрле булса да, диннәрнең нигезендә бердәй төшенчә ята.

Безнең чорда иң зур бәяләнә торган нәрсә – уңышка ирешү. Һәрбер кеше уңыш яуларга, һич югында үзен уңышлы итеп күрсәтергә омтыла. Һәм бу туктаусыз рәвештә кеше аңына сеңдерелә. Радио, телевидение, интернет шуны талкый. Матбугат чараларына кино, театр, әдәбият кушыла. Уңыш серен ачарга вәгъдә иткән миллионнарча китаплар дөнья күрә. Уңыш әле ул нәрсәнедер җирена җиткереп, яхшы нәтиҗәләргә ирешү генә булып калмый, ә «җиңү» төшенчәсе белән янәшә куела. Җиңүне без изге төшенчә дип кабул итәргә күнеккәнбез. Үз кимчелекләреңне, тормыш авырлыкларын, юлыңда торган каршылыкларны җиңү акрылап кына дәгъвачыларыңны (конкурентларны), дошманнарыңны җиңүгә әверелә. «Җиңүчеләр һәрчак хаклы», «Җиңүгә илткән ысулларның барысы да яхшы» (Изге китап үтермәскә, урлашмаска, алдашмаска, зина кылмаска өндәгәндә) кебегрәк тәгъбирләр һич кире каккысыз хакыйкать кебек тә тоелып китә.

Әмма бер нәрсә бар. Җиңү ул оргазм кебек. Оргазмнан соң һәрвакыт оргазмсын тынып кала. Иң югары ноктага менгәннән соң, тагы да югарырак менеп булмый. Аннан соң бары тик төшеп кенә була. Хәтта җенси мөнәсәбәтләрнең дә төп максаты – нәселне дәвам итү, ә ләззәткә ирешү – бары тик кызыксындыру чарасы гына. Дәртләндерү премиясе сыманрак. Тик без җиңү даулыйбыз. Җиңү бәхет китерер сыман тоела.

Алай түгел ул. Безнең болай дип уйлавыбыз – бары тик чорлар шаукымына бирелү, һәр тарафтан яңгыраган мәгълүмат агымына каршы тора алмаслык дәрәҗәдә көчсезлек нәтиҗәсе. Җиңү беркайчан да мәҗбүри түгел. Ул хәтта кирәкми дә. Вак-төяк эшләрдә аз-маз гына, бәлки, мөмкиндер, әмма зур нәрсәләрдә җиңәргә ярамый. Бу мин әйткән фикер генә түгел, әнә буддизм да, даосизм да, ислам дине дә шул хакта искәртеп тора. Инь – янь тигезлеге, күңел тынычлыгын бозарга ярамый, ди. Тарих та шуны күрсәтә. Һәрбер зур җиңү ул – бәрелештә уңышка ирешүнең иң югары ноктасы. Аннан соң югарырак менеп, яхшырак нәтиҗәләргә ирешеп булмый, аннан соң фәкать түбән тәгәрәү һәм таркалу гына көтә. Теләсә кайсы империя тарихына күз салыгыз, бөек патшаларны, ханнарны, корольләрне искә төшерегез. Җиңүләрнең берсе дә берәүгә дә бәхет китермәгән. Җиңү ул бәхет түгел, ә җиңелүнең соңлап килүе генә.

Рухи канәгатьлек һәм күңел тынычлыгы алып килгән һәрбер гамәл – җиңү. Әгәр шулардан мәхрүм итә икән, бу җиңү түгел, ә фаҗига.

Без боларның барысын да беләбез инде. Тик барыбер җиңү теләге тынгы бирми. Җиңүгә омтылу ул – кеше табигатенең бер өлеше бугай.



Уйлы күңел уйлана

Дүртенче буын

Авылда дүртенче буын туганнар шактый. Әни дә, әти дә шушы авылныкы булгач, моңа аптырыйсы да юктыр. Өстәвенә элек бездә дә авыл егетләре күпчелек үзебезнең авыл кызларына өйләнгән.

Без яшьрәк чакта да әле андыйлар күп иде. Хәзер инде үзебезнең авылныкылар бергә кавышмаганга ике-өч дистә еллап вакыт үткән. Өстәвенә, читтән килеп, кайтып урнашучылар да бар. Моннан ике дистә еллап элек, «Катнаш никахлар күп булмаса да, авылыбызның «үз», ягъни «коренной» хатын-кызлары читтән килүчеләрдән бермә-бер ким калган икән. 60 хуҗалыклы авылымда бүген 27(!) авылдан җыелган халык яши», – дип язган булганмын, бүген инде бу сан тагын да артыграктыр. Бу хакта мин генә уйланмыйм икән, элекке авылдашым да: «Төнлә йоклый алмый яткан вакытта авыл урамын әллә ничә кат әйләнеп санадым: авылларда яшьләр клубка йөргән чакта безнең авыл советына кергән дүрт авыл яшьләре үзара бик күп өйләнешкән. Үзебезнең авылныкылар белән гаилә корган 22 парны санадым, тагын утыз бере күрше салавычныкылар белән парлашкан. Һәм мондый гаиләләрнең барысында да төп йорт сакланган, әлеге нигезләрдә балалары яши», – дигән иде.

Ә бит авыл дигәндә бер-береңне биш бармагыңдай белә, бер-береңә ышана, аның өчен якын туганыңдай кайгыра һәм сөенә, кирәк чакта ярдәмгә ашыга, бер-берсен яклый һәм саклый торган бердәм кабилә күз алдына килә. Авыллар тарихына күз салсаң да, күп очракта аларга бер яки берничә гаилә нигез салган. Бу да үзенә күрә авылга әнә шундый туганнарча мөнәсәбәт, шундый язмыш юрау кебек тоела. Үз авылы эчендә генә чәчләре чәчкә бәйләнгән парлар арту сәбәпле дә, авыллардагы нәсел җепләре бер-ике нәселгә барып тоташкан. Ягъни тулы бер авыл бер-берсенә «чыбык очы туган» тиеш булган. Авылның үзәк тамыры да шул булгандыр… Кызганычка, бездә дә күп нәрсә үзгәрде шул. Читтән килгәннәр әле бездә берничә буынга кадәр тармакланганчы берничә буын алышынырга кирәк ләбаса.

Бала чакта да, әле аннан соң да миңа икенче, өченче буын туганнар якын, ә инде дүртенче буыннар бик ерак – «чыбык очы туганнар» гына булып тоела иде. Күңелләренә кереп калсын дигәндер инде, әни бала чакта ук әнә шул «чыбык очлары» турында күп сөйли иде. «Болар шул яктан туган, болар – бу яктан…» Бер гаиләдән ирле-хатынлы кешеләрнең ике яктан да дүртенче буын булганнары да бар. Дөрес, хәзер инде арабызда бер-беребезнең туган икәнлекне белмәүчеләр дә, туганлыкка санамаучылар да бар. Һич тә гаепләп язуым түгел, әйтәм бит, авылда андыйлар шактый. Өстәвенә һәр гаилә үзе еллар үткән саен зурая, тармаклана. Шул сәбәпле араларның ерагаюына, бер-беребездән читләшүгә гаҗәпләнәсе дә юк бугай. Динебез дә инде дүртенче буын туганнарга өйләнешергә, бергә гаилә корырга рөхсәт итә икән, димәк, бәйләнешнең ерагая баруы хактыр. Әмма шул ук вакытта җиде буынга кадәр нәселеңне белү (аннан артса, тагын да шәп) бик мәслихәт, тикмәгә генә җиде буынга кадәр нәсел-нәсәбен өйрәнеп, гаилә корырга киңәш ителмидер. Шөкер, соңгы вакытта буыннар арасындагы бәйләнешләрне өйрәнү, нәсел шәҗәрәләре төзү бик матур гадәткә әйләнде. Шәҗәрәләрне матур, зәвыклы итеп ясап, иң күренекле урынга элү, балалар бакчаларыннан башлап шәҗәрә бәйрәмнәре, конкурс-бәйгеләр үткәрү ниндидер бер мода, плюс өчен үткәрелгән чаралар булып калмас, нәсел җепләрен ныгытуда, буыннарны бер-берсенә якынайтуда да ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Буыннар якынлыгы димәктән, баксаң, дүртенче буын туганнар әллә ни ерак та түгел, киресенчә, бик якын икән бит. Бу кадәресен үзебез – дүрт бертуган тармаклана башлагач кына чын-чыннан аңладым, ахрысы. Бездән туган балалар бер-берсенә икенче буын туганнар була бит, ә безгә аларның һәркайсы үз балабыздай якын. Аларның кечкенә генә уңышларына да чын ихластан сөенешәбез, әз генә авырып китсәләр, мәшәкать-проблемалары булса да, төн йокыбыз кача. Алардан туган балалар – өченче буын – инде ике дистәгә якынлашып килсә дә, һәрберсе шулай ук бик кадерле. Аларның да һәммәсен әйбәт итәсе, алар турында һәрчак яхшы хәбәрләр генә ишетәсе килә. Шөкер, икенче-өченче буыннарыбыз берсен-берсе әйбәт белә, мөмкинлек булган саен аралашып яшиләр. Ә бит алардан туачак балалар бер-берсенә дүртенче буын булачак лабаса! Күр әле: нинди якынлык! Кул сузымы ара гына икән бит…

Кул сузымы ара гына… Тик һәр тармак бит әле үзе дә тармакчыкларга бүленә. Ул тармакчыкларга башка нәсел «ботак»лары да кушыла. Якынаю-ерагаюларда бу кадәресе дә роль уйныйдыр. Тик шунысы да бар: бер ерагайган араларны якынайту, туганлыкны ялгау җиңел эш түгел. Бигрәк тә бүгенге кебек, һәрберебез «үз казаны»нда кайный торган чакта. Кайчандыр үзем «чыбык очы туганнар» дип санаган дүртенче буыныбыз, безнең дәвамчылар бу хакыйкатьне аңлармы?

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

2024 гаилә елы

СЫНАТМАС ЙӨРӘК

«Чын бәхетне гөрләп торган балалар тавышыннан таптым». Арча районындагы Илдус авылында яшәүче җиде бала анасы Гөлгенә Хәбибрахманова сүзләре бу. Җиде сабыйга гомер биргән ананың күңел сандыгы шыплап тулган икән лә. Акрын гына шул сандыкны барладык…

Гөлгенә Хәбибрахмановның шәхси архивыннан

Язмышка үпкәләми, «балалар» дип яши Гөлгенә Хәбибрахманова.

Гөлгенә апа да, ире Айдар да – ишле гаиләдә үскән кешеләр. Ул үзе Арча районының Шушмабаш авылыннан, тормыш иптәше Шекәдән. Хәбибрахмановлар оясыннан Тамчы, Айгөл, Айтуган, Дамир, Данис, Надир, Самат исемле егет-кызлар үсеп чыккан. Гөлгенә апа – «Ана даны» медале иясе дә. Хәер, Гөлгенә апа кебекләргә һәйкәл куйсаң да, аз булыр әле ул.

– Үземнең дә, иремнең дә әти-әнисе безне бер-беребезне якларга, туганлык хисләрен изге итеп сакларга өйрәттеләр. Гаилә коргач, Аллаһы Тәгалә миңа да җиде бала анасы булырга насыйп итте. Без һәр баланы теләп, яратып алып кайттык. Чын бәхетне менә шушы балалар тавышыннан, шаулап торган гаиләдә таптык, – ди ул.

Ишле гаилә эчендә мәшәкате дә чиксез, җитешсезлекләре дә аз булмый, билгеле. Моны Гөлгенә апа да яшерми. Тик йөрәк тулы ярату хисе булганда, боларга игътибар итәсеңме соң инде?! Игътибар ителсә дә, онытыла.

– Сабыйларны ихлас ярату, алар белән горурлану авырлыкларны җиңәргә ярдәм итте. Без беркайчан тормышыбыздан зарланмадык, киресенчә, һәр баланың шатлыгын уртак итеп, аның белән бергә көенеп, бергә сөенеп яшәдек, – ди Гөлгенә Хәбибрахманова.

Ләкин… Күп була ананың тормышында «ләкин» дип, аны туктатырга тырышкан вакытлар…

2015 елда кечкенә уллары Самат зәһәр авыруга дучар була. Табиблар әле бер яше дә тулмаган нарасыйга кан рагы куркыныч диагнозы куя. Әле дөньяның ямен дә, тәмен дә татырга өлгермәгән баланы үлем күләгәсе сагалап йөри башлый. Хастаханә ишекләре, ак халатлы табиблар, бетмәс-төкәнмәс тикшеренүләр, баланың күзгә карап үзгәрүе, аңа җелек күчереп утыртулар… Ана йөрәге һәр балага бирәү түгел лә, бирәү генә! Гөлгенә апаның сабырлыгын сынар мизгелләр була бу. Самат белән туган йортларыннан еракта дәваланган мизгелдә «Өйдәгеләр нихәлләрдә икән?» – дип аз өзгәләнми ул. Дәвалану узган көннәрдә җиде баланың берсе беренче сыйныфка укырга да керергә тиеш була әле. Ләкин… Мәктәп кайгысымы соң?!

Хәбибрахмановлар үзләре кичергәнне, дошманга да язмасын дип, хәзергесенә шөкер итеп яши.

– Бу хәсрәттән сыгылып төшмәдек, – ди ана. – Аллаһы Тәгаләнең ярдәме, барлык туганнар, күршеләр, авылдашлар, изге җанлы мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән бу чирдән дәваланып кайттык. Айдарымның көчле җилкәсе астында булу да, балаларымның берсе өчен берсе барысын да эшләргә әзер торулары, бердәмлекләре миңа зур көч бирде.

Тик… Җайланган тормышның ишеген кабат кара кайгы шакый. Өч ай элек балаларны ятим, Гөлгенә апаны сыңар канат итеп, Айдары мәңгелеккә күзләрен йома…

– Балаларымның кадерле әтисе, минем яраткан Айдарым, йортыбызның терәге булган кешене югалту хәсрәте – йөрәгебез ярасы. Авыр, бик авыр, – ди Гөлгенә апа. – Айдарым бик төгәл, таләпчән, намуслы, ярдәмчел, кирәк урында шаян да була белде. Исемдә: бервакыт 8 Март бәйрәме алдыннан барыбыз да бергә пилмән бөктек. Шунда мин Айдарыма, телевизорда ашарга гел ирләр пешерә, берәр пешерү эшен синә йөклим әле, дип шаярттым. Балаларның 8 Март бәйрәме концертыннан кайтышыма кәстрүл тутырып пилмән пешереп куйган иде бу! «Ашарга пешерә алмый әллә, дип уйлыйсыңмы? Менә, Гөлгенәм, бәйрәм ашы итеп пилмән пешердем!» – дип каршы алды. Айдарымның урыны җәннәттә булсын иде!

Яшәргә дә яшәргә, балалар, оныклар шатлыгын тоеп, бәхетле картлыкка парлап керергә насыйп булмаса да, Гөлгенә апа зарланмый.

– Үземне канаты каерылган кош сыман хис итсәм дә, минем өчен өзелеп торган балаларым хакына тырышып яшәргә, көчле булырга кирәк, дим. Ходай ташламас, – ди әңгәмәдәшебез. – Кайгыларга бирешмичә, сабыр булып, балаларымның милләтебезнең дәвамы, илебезгә лаеклы, авылыбыз терәге булып үсеп җитүләрен телим. Аларның игелекләрен күрергә насыйп ит, Раббым, дим.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БАЛА БЕТСӘ, БАР ДА БЕТӘ

Авыл җаны

Кайберәүләрне күрүгә, «бигрәк үз урынында бит бу кеше» дип сокланасың. Димәк, үзе дә бәхетле, аның янәшәсендәгеләр дә: тәмен-ямен белеп эшләгән эшең булганда, кәеф күтәренке, уйлар якты, барлык кеше дә яхшы. Башкача була алмый, чөнки бу очракта гормоннарның (серотонин, окситоцин, дофамин, эндорфин) уңай корылышлары өстенлек итә.

Үзебезнең авыл балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче Гөлфинурны күргәч, шундый уйлар туган иде. Дөрес, үзен якыннанрак күргәнче энекәшнең гаиләсе, аларның кызлары Ясминә аша белдем мин аны. «Бигрәк унды монысы апаларыннан», «Ниләр генә эшләмиләр»… Ниләр эшләгәннәрен социаль челтәр аша да күреп торабыз: апалары көн саен видеолар куя. Әле уен уйныйлар, әле җимлек ясыйлар, әле – рәсем, әле табигать белән танышалар… Табигать белән дә рәсем аша гына танышып ятмыйлар: үзләре тотып, күзәтеп, карап, иснәп өйрәнәләр дөньяны. Әллә шуңа, барлык балалар да әйтә торган «садикка бармыйм бүген» дигән сүзне бик-бик сирәк әйтә Ясминә. Анда да сәбәп бер: бакчада көндез йоклаталар! Бер «йомшарткыч» ягы да бар икән тагын – апалары әкият укып йоклата икән үзләрен.

Гөлфинур турында язу уе исә аның «Ел тәрбиячесе» конкурсында район этабында җиңеп, Түбән Камада зона ярышларында катнашып йөрүен белгәч килде. Районда җиңүче булуына әллә ни аптырамадым; күзеңне йомсаң да күренә торган кешеләр була. Тукайча әйтсәк, «эшкә бирсәң чын күңел…» – «эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш».

Гөлфинур – күрше Шахмай авылы кызы. Утыз биш яшьтә, ире белән ике ул үстерәләр. Тәрбияче буларак дүрт кенә ел эшли әле. Авылда төпләнеп яши башлаганчы, Чаллыда торып алган: «Шәһәргә өч мәртәбә китеп карадым, ләкин күңел ятмады, барыбер авыл тартты», – ди ул. Авылпәрвәрләрнең күбесе кебек ул да: «Авылда яшәү бик рәхәт бит. Саф һава, табигать. Үз бакчаңа чыгып, берәр үлән алып керсәң дә, күңел күтәрелә», – ди. Әлбәттә, авыл тормышының кыенлык китерә торган якларын да күрә. Бөтен бер авылга кечкенә генә бер кибет, мәктәп башлангычка калды, ул да балалар бакчасы бинасына күчерелде; даруханә, хастаханә ерак. Быел исә карлы-буранлы кыш юллар проблемасын да күрсәтеп алды. Шундый көннәрдә берәрсенә ашыгыч ярдәм кирәк булса, аның вакытында килә алмавы көн кебек ачык. Мондый хәлләр соңгы елларда авылда техника, ферма, мал-туар калдырмаганга килеп чыга башлады. Шуңа күпләр колхоз чорын сагына.

Гөлфинур Мирьякупованы да – булдыклы, тырыш, ачык күңелле тәрбияче апабызны – авылда балалар бетеп, кайда да булса башка җирдә эш эзләү перспективасы борчый. Үземне башка өлкәдә күз алдына да китерә алмыйм, ди ул. «Балаларны яратам. Алар белән сөйләшү дә башкача бит. Ул әйтеп бетермәслек эмоцияләр, сораулар, кызыксынучан күзләр. Аннары бергәләп шул сорауларга җавап эзләү; яңаны өйрәтү. Балалар белән эшләгәндә, күзләрем яна башлый минем, үзем дә сизәм», – ди.

Әлегә бакчада – эреле-ваклы тугыз бала. Иң мөһиме – исән-сау булып, даими йөреп торсыннар, дип тели. Балалар күбрәк булса, тагын да әйбәт булыр иде дә бит, дип көрсенә. Авыл киләчәген күпләр шикелле үк «өстәге»ләр теләге-тырышлыгына бәйли: «Телиләр икән – бар авыл, теләмәсәләр – иртәгә үк юк ул». Без, авыл бетмәсен, дип тырышып хезмәт куябыз, өмет белән яшибез, тик бар да бездән генә тормый, ди.

Шуңа күрә бүгенге көн белән яши. Буш вакытларын уллары белән уздырырга тырыша. Кышын алар белән тау шуарга ярата. Әле икесен дә чаңгыда йөрергә өйрәтә башлаган. Хыялы – балаларга диңгез күрсәтү.

Менә шундый эш кешеләренең гап-гади хыяллары чәлпәрәмә килмәсен иде инде. Буй җитмәслек хыял түгел бит – Куршевель, шәхси самолетлар алу турында хыялланмыйлар. Балаларын имин тормышта үстереп, дөньяның матур якларын мөмкин кадәр күбрәк күрсәтү турында гына уйлары. Үз туган ягында кешеләргә файдалы булып, аларның ихтирамын тоеп, рәхмәтен ишетеп яшәргә тели. Күпме бу, азмы?

Лилия ФӘТТАХОВА

Соклану

Хат ташый игезәкләр

Сабада яшәүче Гөлгенә белән Гөлнара хат ташучы булып эшли. Үзләре – Теләче кызлары. Менә инде 14 ел авыр сумкаларын җилкәләренә асып, өйдән-өйгә газета-журналлар ташый алар. Укымый түгел, матбугатны халык яратып укый. Хат язышу гадәте дә бетмәгән әле.

– Хат ташучы, өйгә кергәч, безгә бер хезмәткәр кирәк, диде. Үзе белән мине почтага алып китте. Шуннан барысы да башланды инде. Аннан туганым Гөлнара да иярде. Менә шулай икенче дистә китте. Эшебез авыр түгел. Бик яратып башкарабыз, – ди Гөлгенә Булатова.

51 яшь булса да, җилдән җитез үзләре. Йөри-йөри тиз атларга өйрәнеп беткәннәр, күрәсең. Форма сакларга спорт белән шөгыльләнү дә булыша. Бергәләшеп турникта тартылалар, Боз сараена шугалакка йөриләр. Роликта шуарга яраталар. Җәен почтаны сәпидтә тараталар. Менә шундый актив үзләре.

– Көнгә ничә чакрым ара үтәсез? – дип сорадык.

– Чутсыз, без аны санамыйбыз. Саф һавада йөрү бик файдалы. Табигать сулышны киңәйтә. Кошларның сайраган тавышларын ишетеп, өй кыегыннан тамчылар тамганын күреп кайтабыз. Офиста утырсаң, матурлыкны күреп булмый бит. Дистәдән артык урамны урыйбыз. Әле газета гына түгел, пенсияләр таратасы, коммуналь хезмәт өчен түләү квитанцияләре, бандерольләр, хатлар, реклама материаллары өләшәсе дә бар. Товарын да сатарга кирәк. Хәзерге вакытта орлыклар сатабыз. Без эшебезне вакытында үтәргә яратабыз, – ди Гөлнара.

Хат ташучылар булганда, халык та ил-көн яңалыклары белән вакытында таныша, рухи азык туплый. Газета да искерми, хатлар да соңармый, кыскасы. Ә бит почта таратучылар җитмәгән кайбер авылларда моңа кызыгырга гына кала.

Әлбәттә, җәяү йөрү ардырта. Кызлар өйгә арып кайтуларын да яшерми. «Диванга кайтып егылабыз да, ял иткәч, иртәгесен елмаеп тагын чыгып китәбез… Көн артыннан көн туа. Шулай гомер уза. Яратмасаң, бу кадәр озак эшләп булмый», – ди алар. Тик әйтер сүзләре бар: товар сатуны бетерсеннәр, хезмәт хакын арттырсыннар. 16 мең сум хезмәт хакына гына ерак китеп булмый шул. Хат ташучының да кешечә яшисе килә бит.

Сәрия МИФТАХОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Гаилә истәлекләре

ГЕЛ «БИШЛЕ»ГӘ УКЫГАН

Апаем иртә китте дөньядан. 1991 елда, 53 яше дә тулмаган иде... Тарих фәннәре докторы, профессор Саттарова Флера Фәтхрахман кызы, кайда гына укыса да – мәктәптә, Арча педучилищесында, Казан педагогия институтында, Фәннәр академиясе аспирантурасында – гел «бишле» билгеләренә генә укыган тиран белемле гадел укытучы иде. Фәнни коммунизм... Студентларга шуны укытты... Табигате белән чиста күңелле, дәреслекне бар нәрсәдән дә өстен күргән, туган җанлы апаебыз мандолинада, баянда уйный һәм гаҗәеп матур җырлый иде. Тавышы беребезнекенә дә охшаман, үтә дә моңлы иде. Кулына баянын алса, үзенең яраткан җырын:

«Зәңгәр чәчәк ата торган
Гөлләр дә була икән.
Дөнья булгач, бик сагынган
Көннәр дә була икән...» –

дип җырлый иде. Пединститутта узган байтак чараларда чыгышлар ясады апаем. Пластинкалардан тыңлап, бик күп чит телдә башкарылган җырларны да белә иде. Бигрәк тә Һиндстан җырчыларының. «Мин кайчан да булса Һиндстанга барам әле», – дип әйткәне әле дә исемдә.

Чигү белән мавыга иде апаем. Русча әйтәләр бит әле «вышивка крестиком» дип. Менә шул ысул белән чигелгәннәрне матур итеп өйләренең диварларына урнаштыра иде – пыяла астына, рамга куеп.

ЯШЕРЕП КУЙЫЙКМЫ ӘЛЛӘ?..

Әниемнең сөйләгәне хәтердә: апаем, Арча педучилищесында укыганда, миңа матур-матур күлмәкләр теккәләгән. Мин бик бәләкәй чакларда булган бу (яшел белән чигелгән карасын әле дә хәтерлим). Мин, шул күлмәкләрне шкаф тартмасыннан чыгарып, барысын да киеп карый торган булганмын. Аннан, билгеле инде, кайсыберсен озаграк та киеп йөргәнмен. Кыскасы, барлык күлмәкләр дә берьюлы, алыш-тилеш (безнең якта шулай әйтәләр) киелгән, «әйләнеш»тә булган... Димәк, берьюлы керләнәчәк, тузачак бит инде. Бу хәл көн саен диярлек кабатлана икән. Шушы хәлне күреп торган апаем: «Әнием, бер-икесен яшереп куйыйкмы әллә?» – дип әйтә торган булган.

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА.
Казан

ru.freepik.com

СУ ГЫНА

Болыннарга чыгып, күп сокландым,
Көмеш диеп, таңнар чыгына.
Бүген карыйм, чәчәк күзләрендә
Көмеш түгел, бары су гына.

Чишмәләрдә челтер-челтер килеп
Ага, дия идем, җыр гына.
Бүген тыңлыйм, улак эчләрендә
Җыр түгел шул, бары су гына.

Күпме шигырь язып куандым мин,
Җәүһәр тездем, дип, һәр юлына.
Укып карыйм бүген, кубесендә
Җәүһәр түгел, бары су гына.

Нинди гүзәл, нинди бай булды, дип
Сокландым мин гомер юлыма.
Бүген баксам, анда гомер булып
Агып ята икән су гына.

Гәрәй РӘХИМ

БЕЛ КАДЕРЕН

Мин Сарманда үстем. Җәй көне, бераз вакыт булуга, Минзәлә елгасының Сухан койрыгы дигән өлешенә су коеныра йөгерә идек. Без су кереп ятканда, сызгыра-сызгыра, кычкыра-кычкыра, көлешә-көлешә, малайлар да су буена төшә. Без исә алардан качу ягын карыйбыз, яр буйлап алга таба йөгерәбез. Шуны гына көткәндәй, алар да йөгерә. Колхоз эшеннән кайтуга, әнкәйләр дә елга буен үз итә. Елга суын: «Көмештәй су бу», – дия торганнар иде. Бу әйтемнең мәгънәсенә мин соңрак – тормыш тәҗрибәсен туплый-туплый төшендем. Һәр урамда берничә кое бар иде. Янәшә-тирәдә яшәүчеләр һәр елны иртә җәйдә коеларның суларын алып бетерәләр дә берәр кыюрак малайны, чиләккә утыртып, чүп-чардан чистартырга кое төбенә төшерәләр. Тегеләй чүп-чарны чиләккә тутыра да чиләкне өскә күтәрергә әмер бирә. Чыгырлы яисә сиртмәле коеларны шулай чистарттылар.

Язмыш мине сусыз бер авылга эшкә җибәрде. Дөрес, урамда коелар бар, әмма аларның суы эчәргә яраксыз, эчәргә яраклы кое – колонка авылның таулырак өлешендә иде. Анда исә һәрвакыт чират. Йә бик иртә таңда, йә караңгы төшкәч барсаң гына инде. Җәлил бистәсенә күчкәч кенә суга рәхәтләндек. Авылдагы барлык чаршау, тәрәзә пәрдәләрен, юрган-мендәр тышларын Җәлилдән ташып юдык. Ирем: «Юып, урын-җир кирәк-яракларын туздырып бетерәсең инде», – дип көлә иде.

vk.com

Бервакыт күршегә йомыш белән кердем. Күршем Бразилия сериалына текәлгән, бүлмәләрен пар баскан, краннарыннан кайнар су шаулап ага. Әлләнишләп киттем. «Кранygыз ватылдымы әллә?» – дим. «Эшли. Савыт-сабаны юарга куйган идем», – ди хуҗабикә. Кул белән юып азапланмый, янәсе.

Су яшәү өчен балачакта да, олыгайгач та һава кебек үк кирәк, зур байлык ул, исраф итмик, кадерен белик.

Халисә ШӘЙДУЛЛИНА.
Сарман районы

«ВТ» архивыннан/Дмитрий Бунтуков

Компьютерсыз балачак

Мәңге үтмәс кебек тоела иде безнең яшьлек еллары. Әмма вакыт үзенекен итте һәм итә. Хатирәләр генә хәтердә яңарганнан-яңара, һич онытылмый икән алар.

...Абый-апалардан калган пәлтәне киеп, шыгырдап торган кар өстеннән, болын буйлап, мәктәпкә бара идек. Укудан кайткач, бер телем кара ипигә каймак ягып, шуның белән бер чынаяк чәй эчеп, әти кушып калдырган эшләрне эшләгәч кенә уйнарга чабабыз. Рәхәтләнеп чана шудык, качышлы уйнадык, кар атышып уйнау гадәте дә бар иде. Кыланмышларыбыз озакка сузылса, өйдәгеләр эзли чыга. Юешләнеп беткән өс киемнәрен күреп орышкан вакытлары да булды. Чирли генә күрмәгез, дип әйтүләренә дә күңегеп беткән идек инде.

Уч тутырып кар ашап, пәлтәләргә бозлар катканчы карда аунап, боз сөңгеләрен сындырып кимереп, язгы ташу суларында яланаяк йөреп ничек исән калганбыздыр инде – белмим. Утыз градус салкында да урамнан кермәдек бит. Уеннарны үзебез уйлап чыгарып уйнап үстек. Әле ярый, без үскәндә, компьютер дигәннәре юк иде – җансыз виртуаль уеннар бәхетле балачактан мәхрүм итмәде. Уйнарга уенчык булмаганда, шакмакка шакмакны кадаклап, трактор ясадык. Менә шунда чүкеч тотып, бармакка суга-суга, кадак кагарга өйрәндек. Барыбыз да бер тиң идек, бары – бергә, югы – уртак. Бер-берeңне түбәнсетү, кимсетү безнең өчен ят иде. Тау битләре кардан арынгач, какы, кузгалак, лапас артыннан кычыткан, песи боргагы җыеп ашап, каен суы эчеп рәхәтләндек.

Эшләдек тә, уйнадык та,
Беләкләр дә эштә чыныкты.
Һәр нәрсәнең кадерен белә идек,
Әрәм итмәдек без хәтта валчыкны.
Хөрмәт иттек олы-кечене,
Кадерләп тотып без искене.

Раил ҺАДИЕВ

«Былтыр – 41, быел 42 инде»

Күңелемә 2023 елның Укытучылар һәм остазлар елы буларак билгеләп үтелүе сары май булып ятты. Бик кирәкле гамәл иде бу.

Заманында безне Сафилә апа укытты, бердәнбер югары белемле укытучы иде булса кирәк ул.

Әтнә техникумын тәмамлап килгән иде. Ул агитатор да, клубта лекцияләр дә укый. Үзе – бик яхшы оештыручы, үзе – сәхнәдән төшмичә, җырлап, халыкның күңелен ачучы. Урып-җыю вакытында икенче сменага амбарга эшкә дә менә.

Өченче сыйныфта укыган вакыт. Иртән дәрескә керде дә: «Укучыларым, миңа моннан соң Солтанова дип эндәшерсез. Мин Мансур абыегызга кияүгә чыктым», – диде. Кулымдагы китапларны идәнгә төшереп җибәрдем. Ничек инде фәрештәдәй апа кияүгә чыга алсын?! Ул вакытта шок дигән сүзне белмибез бит әле, шул булган инде ул. Мөхәммәт Мәһдиев тә укытучысының көлдә пешкән бәрәңге ашаганын күреп шаккаткан бит.

1948 ел. Без беренче класска керәсе елны, Димиев фамилияле бик усал укытучы килгән икән, дигән сүз чыкты. Беренче сентябрь көнне күршем – якын туганым Нәкыйп белән мәктәп капкасына кадәр килдек тә, Димиевтән куркып, керми торабыз. Бакчасы мәктәп ихатасына терәлеп торган Нәфисә әби безне чакырып алды да, балалар, китми торыгыз, хәзер чыгам, дип, өенә кереп китте. Озакламый чыгып, безгә ярты йодрык зурлыгында шикәр тоттырды. «Балаларым, мин бәрәңге казыйм, сез чүпләргә киләсез», – дип, безгә эш кушты. Ялгызы гына яши иде ул. Кесәдә ул биргән саллы гына шикәр – ничек тыңламыйсың инде? Шулай итеп ике-өч көн үтте. Әти-әниләр иртән торып эшкә китә, кич караңгыда гына кайталар. Олыларның бездә гамьнәре юк. Авыл көтүен дә иртәнге өчтән-дүрттән калдырмый чыгаралар иде.

Беркөнне Димиев абыебыз урамда эзләп тапты безне. «Кайсыгыз Мәгъдәнур?» – дип сорады. Мин, дидем. «Нәкыйп син буласың инде алай булгач», – дип, безнең белән танышты. Нәкыйптән ничәнче елгы булуын да сорады. «Былтыр 41 идем, быел 42 инде», – дип «чатнатып» җавап бирде Нәкыйп. Димиев Әхтәм абый гаҗәпләнеп карап торды да, иплән кенә: «Иртәгә мәктәпкә килегез инде, яме?» – диде. Шулай итеп аерылыштык. Амбарга әниләр янына менеп: «Менә шундый балаларга белем бирер кара инде», – дип әчен бушаткан.

Без ишеткәнчә усал түгел иде ул. Олы башлы, юан гәүдәле, уртача буйлы укытучы иде. Белеме дүрт класс, диделәр. Озын тәнәфесгә Сафилә ападан эшләтеп, карап, өйрәнеп тора да аннары дәресгә бездән эшләтә. Тәвәккәллеге күренеп тора иде. Аннан озак еллар Шаршан кирпеч заводын җитәкләде. «Чулпыч»ны да бик сагынам, барып чыгам әле», – дип, ачылып сөйләшә иде.

Оет авылыннан килеп укытучы Ногманова Мөнирә апаның җиде класс белеме бар, ул да бик белеп, без аңларлык итеп укытты.

Укытучыларга хөкүмәт тарафыннан да аерым хөрмәт булды, һәр айның бер көнендә кибеткә продукциягә килә иде, аны башта укытучылар сатып ала иде.

Укытучыларга хөрмәтем бүген дә чиксез минем. Һәрбер баланың, һәрбер ата-ананың укытучыны фәрештә кебек күрүләрен телим.

Мәгъдәнур ГАТАУЛЛИН.
Саба районы

Үткәннәргә кире кайтып

ЯТИМЛЕК ФАҖИГАСЕ

Әле дә хәтердә: кыш ул елны карлы-буранлы килде. Буран чыгарга торган шундый көннәрнең берсендә үзәктән биш-алты чакрымда гына урнашкан зур бер авылга килеп киттем дә, эзләгән йортны табып алып, капка келәсенә үрелдем.

Мине чыйбыр буйлап арлы-бирле йөренеп, дөнья куптарып өргән бозау кадәрле эт каршы алды. Бераздан йорт хуҗасы үзе дә күренде. «Кирәкмәс иде инде, – диде ул, нигә килүемне аңлап алгач, – болай да чыкмаган җаны гына бар, үкенә бала».

Ике катлы зур йорт, берсеннән-берсе шәп җиһаз, табын тулы ризык... Карап торырга әйбәт кенә кешеләр үзләре. Нигә сыймады икән болын кадәрле өйгә бер бала?! Хуҗабикә: «Үзе белән сөйләшегез», – диде дә кухня ягына чыгып китте. Кая карама гөлләр булган бүлмәдәге зур диванда бөгәрләнеп яткан ябык гәүдәле яшь хатын, мине күргәч, торып утырырга ашыкмады. Ята бирде. Сөйләшергә, ачылып китәргә дә җыенмады. «Шулай килеп чыкты инде», – диде дә борылып ук ятты.

– Үкенеп, беләм, бәлки, ярдәм итеп булыр, – дидем. Шулай диюгә, ул үзгәреп китте. Өмет тулы яшьле күзләрен миңа текәде. «Шулай дисәгез генә, ә болай үткәнне актарудан мәгънә юк», – диде. Ул миңа табуга ук баладан баш тартуы, аны бала табу йортында калдырып китүе, ә ел дигәндә, кире уйлап, алырга баруы хакында сөйләп ала. Ә үзенең күзләрендә мөлдерәмә яшь. «Бардым, ялвардым, ә алар, соң инде, балагызны уллыкка алдылар, дип, минем белән сөйләшергә дә теләмәделәр. Сиңа ышаныч юк. Баласын бер ташлаган кеше икенче мәртәбә дә шуны эшләргә мөмкин, диделәр. Мин ялгыштым, бу – минем гомеремә җитәрлек зур хатам. Юк, хата гына түгел, зур гөнаһым...»

Саубуллашып чыгып киткәндә, алар миңа: «Булышсагыз икән», – дип калдылар. Кызганыч, бик теләсәм дә, бу четерекле мәсьәләне хәл итәргә ярдәм итә алмадым. Закон һәрвакыт ана ягында икәнен белсәк тә, монысы андый очрак түгел иде шул. Ташлап киткәч, кире кайтарулары...

Моңа инде күп еллар узды. Газиз әнисен бер мәртәбә дә күрмәгән бала да үсеп җиткәндер. Бәлкем, ул бик бәхетледер, ә бәлки – бәхетсездер. Кем гаиләсенә, кем тәрбиясенә килеп эләгә бит бала... Бәлкем, яшь ханым да, кияүгә чыгып, бер-бер артлы балалар тапкандыр. Ул аларны бик яратадыр, олысына бирә алмаган назны аларга бүлеп бирәдер. Яныдагыларын кочкан-үпкән саен читтәгесе исенә төшәдер.

Ничектер шулай килеп чыкты инде: кая гына барсам да, кемнәр белән генә очрашсам да, шушы темага әйләнеп кайтырга, ятимлек фаҗигасе белән күзгә-күз очрашырга туры килә. Әйе, миңа балалар йортларында, яшүсмерләр колонияләрендә булырга, балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссияләре, полиция хезмәткәрләре белән еш аралашырга туры килде. Бала ул әйбер дә, курчак та, уенчык та түгел. Кирәксә, калдырасың, кирәкмәсә, ташлыйсың түгел. Соңыннан үкенерлек хәлгә төшкәнче, ни эшләгәнеңне, ни кылганыңны кат-кат уйларга, балалар йортларына эләккән сабыйларның язмышы турында уйланырга кирәк. Ә аларның ул йортларда, ничек кенә димик, мөстәкыйль тормышка әзерли алмыйлар. Ул йортлардан чыккач, унҗиде-унсигез яшьлек кыз-малайлар кая китә, кемнәр йогынтысына эләгә?!

Унҗиде яше тулгач, балалар йортыннан икесе дә вафат әти-әнисе фатирына кайтып утырган, үзе дә бала гына әле. Тик инде бу яшендә үк ялгызлыкның адәм баласы өчен ни дәрәҗәдә фаҗига булуын аңларга өлгергән, ачысын-төчесен күргән бу кыз тормышны башкача белми дә. Ул әнә үзе инде әни булган. Соңыннан белдем: беренче карашка чиста гына, тыныч кына күренгән ике бүлмәле фатир кичләрен притонга әйләнә икән. Кызның үз янына сыра-хәмер ярата, җинаять юлында йөри торган яшүсмерләр җыеп ятуын күршеләре дә, полиция хезмәткәрләре дә белә булып чыкты. Ә яшь әни үзе төнге кубәләк тә икән әле. Андыйларга ярамый дип әйтеп кара син! «Мин закон бозмыйм», – дип кенә җибәрәләр.

Болай дигәннән, фахишәлек кылып йөргәндә юлда машина таптап киткән хатын, өйдә берүзе утырып калган сабые искә төшә. Нәни өч төн, өч көн елый, берәү дә ишетми (ә бәлкем, ишетергә теләмәгәннәрдер, өч көн елавын каян белгәннәр алайса). Нәтиҗәдә бала үлә. Менә сиңа күршеләр... Гамьсезлек кеше үтерә, дигәнебез шушыдыр.

Мәгълүматларга караганда, мөстәкыйль тормышка аяк баскан ятимнәр, рәхимсез чынбарлык белән йөзгә-йөз очрашканнан соң, кайсы үз-үзенә кул сала, кайсы җинаять юлына баса. Бик азының гына тормышлары уң килә. Язмыш тарафыннан кимсетелгәннәрнең вакытлыча сыеныр тору почмагын ятимнәрне мөстәкыйль тормышка әйрәтү мәктәбе иткәндә генә ул бәхетсезләр язмышында аз гына булса да алга китеш, уңай үзгәрешләр булыр. Моның көн кадагындагы мәсьәлә булуын тормыш үзе күрсәтте инде.

Мәдинә АВЗАЛОВА

Халык кәефе

Нихәлләрдә ятасыз?

Яз уртасы, иң хәерле һәм кадерле ай – рамазан ае уртасына да җиттек. Җиң сызганып, язгы бакча эшләренә керешер көннәргә дә күп калмады. Газета укучыларыбыз нихәлләрдә яшәп ята? Аларның кәефләрен белештек.

Ландыш НИГЪМӘТҖАНОВА,
Татарстанның атказанган артисты:

– Кәефләр әйбәт. Эшлибез, ураза тотабыз, ял итәбез. Гаиләбездә сөенечле вакыйга да бар: күптән түгел олы улыбыз Әнвәр паспортлы булды. Әле менә каникул башланды, авылга кайттык. Барыбыз бергә, иң мөһиме – исән-сау. Димәк, барысы да әйбәт.

Гөлназ ГАТАУЛЛИНА,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы (Чаллы):

– Алты ел декретта утырганнан соң, быел мәктәптә укыта башладым. Яңа гимназиягә эшкә кердем. Төрле мәктәпләрдә эшләгәнем булды. Монысы өй янында гына, бик әйбәт. Элеккеге укучыларым сагындыра, әлбәттә. Шукларын, тәртипсезләрен дә сагынам (*көлә*). Татар телендәге элмә такталарда хаталарны ачыклау бәйгесендә былтыр да катнашкан идем, быел да шул эшне дәвам иттерәбез. Хаталарны һаман да эзләп йөрибез. Күзгә чалынып тора бит. Шулай ук башка бәйгеләрдә катнашабыз. Үзем дә, мәктәптәге укучыларымны да катнаштырам. Татарча концертларга, театрларга йөрергә яратабыз. Башка шәһәрләргә экскурсияләр дә планлаштырып куйдык. Җәй көне Казанга барып кайтырга исәп.

Әнисә РӘХИМОВА,
күпбалалы әни (Казан):

– Мөселманнарның иң изге ае – рамазан ае бара. Бүген унбишенче көн бөтен гаиләбез белән ураза тотабыз. Ифтарларга, мәчетләргә йөрибез. Көндезләрен – эштә, сишәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга йөрим. Балалар каникулга чыкты. Тулаем алганда, бар да әйбәт безнең. Мәскәүдәге трагедия генә кәефне кырды. Күңелдә тынычлык югалды. Беренчедән, кешеләр бик кызганыч, икенчедән, дингә зыян килмәсен дип борчылабыз.

Айназ ГАБИДУЛЛИНА,
блогер (Әлмәт):

– Кәефләр әллә ни түгел. Күңел ачу өлкәсендә эшләгән кеше буларак, иртәгә һәм берсекөнгә гастрольләргә китәргә тиеш идем. Бүген җитәкчедән сорап яздым, ул җавап биргәнче үк, «Юк дип әйтсә, ярар иде», – дип теләп тордым. Илгә килгән кайгы беребезгә дә йогынты ясамыйча калмады, билгеле. Рухи халәт бу көннәрдә бик зәгыйфь. Гаилә, көндәлек эшләр белән шөгыльләнәбез инде. Рамазан ае булгач, ифтарлар үткәрәбез. Бернигә дә карамастан, җан тынычлыгын саклап калырга тырышабыз.

Мөхәррәм МӨХӘММӘТҖАНОВ,
бакчачы-агроном:

– Көннәр җылынды, димәк, ниһаять, язгы бакча эшләренә керешер вакыт җитте. Соңгы көннәр гөлләрне, башка үсемлекләрне корткыч бөҗәкләргә каршы препаратлар белән эшкәртеп үтте. Лимон агачым инде күп итеп чәчәк атуга әзерләнә.

Бу – яз килүнең тагын бер билгесе. Лимон агачының үсә башлавын кыш буе көттем. Тырышлык бушка китмәде. Барлык яфраклары яңарып бетте, яңа ботаклар үсеп чыкты.

Икенче ел шулай яңарабыз. Моннан бер ай элек күп итеп чәчәк бөреләре чыгарып карады, әмма барып чыкмады. Менә хәзер мин теләгәнчә инде. Өр-яңадан зур агач булачак, 15–20 көннән кабат чәчәкләре дә күренер дип ышанам.

Үсемлек тә, йөрәк җылыңны биреп, аңлаша алсаң гына тыңлый, ахры.

Ә мин шуңа балалар сыман шат инде.

Ләйсән САФИНА

«ЧАЙКЫЙ»МЫ, ЮКМЫ?

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНДА – РЭП-ОПЕРА

tinchurinteatr.ru

Спектакльдән цитаталар

«Татарларның «чепырка»сы үзе белән бергә генә туктый!»

«Яшисең килсә, йөгерәсең».

«Һәркемнең шәхси тормышка хакы бар!»

«Нәрсә сөйләсәң дә ярый, мин барыбер сине тыңларга җыенмыйм».

«Чөнки мәгънәсез тормыш алып бару бит – мәгънәсезлек».

«Дөньяга күзегезне ачып карагыз әле! Нинди авыр вакытта яшәгәнегезне аңларсыз!»

Премьера

Флешка, рэп яки мәхәббәт – кайсы мөһимрәк? Күптән түгел Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында узган премьерада әнә шул сорауга җавап эзләделәр. Татар театры сәхнәсендә беренче тапкыр куелган рэп-опера күпчелекне нәрсәсе белән дулкынландырды соң? Шау-шу куптарган спектакльне без дә карап кайттык.

Кыю, заманча, яшьләрнеке. Спектакльне әнә шул өч сүз белән тасвирлап булыр иде. Татар сәхнәсендә мондый спектакльнең куелуы тәүге тапкыр. Темасы, геройлар, сюжет, декорацияләр дә – яңалык. Шуңа күрә фикерләрнең төрле булуы да табигый.

Хип-хопера жанрындагы спектакль 2005 елда оешкан «Иттифак» беренче татар рэп-төркеме иҗатына багышлана. Пьесаны драматург, режиссер Илгиз Зәйниев Тинчурин театры өчен махсус язган.

Хәзерге яшьләр нәрсә белән яши, нинди кыйммәтләрне үз итә? «Җиңел» акча эшләү максатыннан гына буш популярлык яулау омтылышы белән янган буын кая барып чыгар? Спектакльдә төп фикер әнә шундый.

– «Флешка, рэп һәм мәхәббәт» хип-хоперасы яшьләр арасында еш очраган проблемаларны күтәрә. Бу – тормышны заяга уздыру, җиңел тормыш артыннан куу. Хәзерге яшьләр үз дөньяларына бикләнеп яши. Тиз генә видео төшереп, популярлыкка омтылалар. Аларны ул дөньядан чыгарырга кирәк. Спектакльдәге катлаулы, шул ук вакытта актуаль теманы тамашачыга җиңел итеп җиткерергә телибез, – диде театрның баш режиссеры Туфан Имаметдинов. – Хип-хоп – урам культурасы. Яшьләр үз проблемалары турында ачыктан-ачык әйтәләр. Спектакльдә катлы-катлы мәгънәләр юк, барысы да бик гади. Рэпның үзе кебек.

«Флешка, рэп һәм мәхәббәт» хип-хоперасындагы вакыйгалар Казан читендәге районнарның берсендә бара. Спектакльдә 11 персонаж катнаша. Алар арасында җиңел юл белән баерга теләүчеләр дә, кызлар арасында популяр ботаник-хакер да, бандитлар да, «начар» егетләрне сөюче кызлар да бар. Һәрберсе үзләренең «кычкырып» торган фамилияләре белән аерылып тора. Әйтик, Афәринов, Моңнуллин, Башбаштаков, Матурова, Җилбәзәкова. Яшьләр җиңел генә юл белән танылырга һәм баеп китәргә тели, криптовалюта, таткоиннар белән эш итә, Дубайда иркен тормыш турында хыяллана, беренче мәхәббәтен очрата. Сюжеты гади, шуңа аңа артык күп тукталып торуны кирәк дип тапмыйм. Ә менә актерларның образларга керүе аерым игътибарга лаек. Яшьләрнең шул категориясен, аларның характерын, кәефен ничек оста итеп җиткерә тинчуринлылар! Спектакль буе рэп башкаралар. Мимика, бию, хәрәкәтләр турында әйтеп тә торасы юк. Һәр артист үз ролендә койган да куйган. Артем Пискунов – яшь гангстер, Гүзәл Галиуллина – һәрнәрсәгә җиңел караучан, рәхәт тормышка кызыгучы кыз, Рамил Минханов – җае чыккан саен пистолетын терәүче пеләш бандит, Рөстәм Гайзуллин аның иләс-миләсрәк саклаучысын бик төгәл чагылдыра.

Сәхнә бизәлеше шактый заманча иде. Декорацияләр алышына торды (әйтик, бер мизгелдә ишек суыткычка әйләнә, Моңнуллин белән Башбаштаков экрандагы машиналарда узыша). Видеопроекция дә оста кулланылган. Заманча музыка, гадәти булмаган сәхнә бизәлеше, актерларның киемнәре – һәрберсе спектакльне тулыландырды. Димәк, режиссер мохитне тудыра алган.

Җиңелчә комедия криминал белән тулы. Вакыты-вакыты белән Тарантино фильмнарын хәтерләтеп җибәрде хәтта. Пистолетлар белән янап йөгереп йөрүче персонажлар... Кайбер мизгелләре артык ясалма, чиктән тыш арттырылган кебек тоелды. Шул исәптән хатын-кыз образларын сексуаль объектка кайтарып калу...

Матурова ролен башкаручы Тинчурин театры артисткасы Гүзәл Галиуллинага рольгә керү өчен шактый үзгәрергә туры килгән.

– Спектакльнең форматы яңа караш, төрле яктан якын килеп эшләүне сорый. Рэпны да, хип-хоп стильләрен дә өйрәнүне таләп итә. Минем өчен, гомумән, барлык артистлар өчен бу – яңа тәҗрибә. Роль өчен шактый үзгәрергә туры килде, – ди Гүзәл Галиуллина. – Рэп, хип-хоп стиленең үз атмосферасы бар. Монда без гадәти драма артистлары кебек элеккечә уйный алмыйбыз. Бу – башка стиль, башка мөнәсәбәтләр. Минем персонажым, исеменнән аңлашылганча, матур тормыш артыннан чаба. Аны да аңларга була.

Спектакльгә «Иттифак» төркеме өчен генә килүчеләр булуына һәм булачагына шик юк. Җырларында берничә буын үскән, кемнеңдер үсмерлек, кемнеңдер яшьлек музыкасы булган төркем җырларын ишетү күңелгә бер рәхәтлек бирде.

– Безнең җырларны тыңлап үскән буын хәзерге мәдәнияттә бик күрсәтелмәгән. Спектакльне җырларыбызның яңа тормышы дип әйтергә була. Сәхнәгә куелып, аны тамашачы ишетеп кенә түгел, күреп, тоеп, үзе аша үткәрә алачак. Текстны укыгач, үзебез өчен дә яңа мәгънәләр ачтык, музыканы киңрәк аңлый башладык, – ди «Иттифак» төркеменә һәм «Yummy music» лэйблына нигез салучы Ильяс Гафаров.

Премьераның беренче көнендә ярты зал студентлар һәм яшьләр булса, залның шактый өлеше урта, өлкән буын кешеләре иде. Шушы урында ирексездән спектакльнең ни дәрәҗәдә театр тамашачысына туры килүе турында уйланасың. Театрга яшьләрне җәлеп итү – икенче мәсьәлә. Һәр спектакльдән тирән мәгънә эзләүче тамашачы мондыйга беркайчан да ияләнеп бетә алмас, мөгаен...

Ләйсән САФИНА

Соклану

Илдар Мөхәммәтҗанов

БАЛТА ОСТАЛАРЫ:

«АГАЧНЫҢ ҖАНЫ БАР»

Биектау районының Олы Битаман авылында яшәүче әтиле-уллы осталар Нияз һәм Илдар Маликовлар агачның бөтен серен белә.

– Мин әтине бөтенләй белмим. Миңа 1 яшь булганда ул, сугышка китеп, шунда ятып калган, – дип искә ала Нияз абый. – Әти дә кулга оста булгандыр дип уйлыйм. Ясаган урындыклары, капкалары хәтеремдә калган. Үземнең дә балачакта ук кулдан кадак, чүкеч төшмәде, тегене-моны ясап, бармакның исән җире калмый торган иде. Без кечкенә чакта авыл миче бар иде бит. Мин һәрвакыт шуның каршында нәрсәдер эшли идем. Тегермәне дә, кул белән әйләндереп йөри торган арбалары да – берсе дә игътибардан читтә калмады.

Ирле-хатынлы Рахилә һәм Нияз Маликовлар 39ар ел мәктәптә укытканнар. Нияз абый физика һәм математика, информатикадан белем бирсә, Рахилә апа география серләренә төшендергән. Дүрт дистә ел эчендә балаларга кадак, чүкеч тоттырып, ир-егет һөнәрен өйрәтүдә дә Нияз абыйның роле зур булган.

– Укытучыны бервакытта да югары хезмәт хаклары белән куандырмадылар. Гел акча җиткезеп булмый, бурычлар да җыелып кына тора иде. Шул вакытта мәктәпкә зур шкафлар ясап бирдем. 1981 елда ясаган шкафларым әле дә исән. Шуннан соң башка заказлар да алырга, тормышны алып барырга үзебезгә ныклап тырышырга туры килде, – ди ул.

Лаеклы ялга чыккач исә, Нияз Маликовның һөнәре күңел юанычына әверелә. Күпләп урындыклар, тәрәзә кысалары, өстәлләр ясый башлый. Остаханәсендә ялгызы гына калганда да беренче чиратта үзенең остаз икәнлеген онытмый ул. Гаделлек, сабырлык эш-гамәлләрендә генә түгел, уй-фикерләр чисталыгында, тырышлыгында да чагылыш таба.

– Пенсиягә чыккач, бу эш тагын да кирәгрәк булды әле. Вакытны телевизор карап, диванда ятып кына уздырып булмый бит. Аннан соң кулда эш булу – үзеңне кемгәдер кирәкле итеп тою өчен дә әйбәт. Агач эшенә бер кереп китсәң, чыгып булмый. Ул кызыклы китап укыган шикелле үзенә суырып ала. Ниятләгән эшең барып чыкса, күңелдә канәгатьлек хисе туа. Ул кешегә дә ошаса, әлеге хис тагын да көчәя. Мин нарат, чыршы белән ешрак эшләдем, чөнки алар эшкәртүгә яхшы бирелә, чыдам. Юкәдән исә тәрәзә өлгеләренә бизәкләр кисәргә уңайлы, – ди Нияз абый.

Бүген аңа – 83 яшь, шуңа күрә соңгы бер-ике елда кешеләрдән заказлар алмый башлаган. Аның каравы әтисенең эшен үзләре белән бергә төп йортта яшәүче улы Илдар дәвам иттерә. Зур, купшы йортларында барысын да үз куллары белән булдырып чыккан Маликовлар. Әтиле-уллы чит кешедән бер кадак та кактырмаганнар.

– Хезмәт дәресе укытканда, Илдар гел минем янда була торган иде. Шул вакытта ук барысын да сеңдереп барган, ахрысы. Кызыксынуы да шул чакларда кабынгандыр, – ди Нияз абый.

Хәер, кул эше остасы булуы белән генә түгел, остазлыгы белән дә әти-әнисе юлыннан киткән Илдар Маликов. 25 ел мәктәптә белем биргән ул.

– Мәктәптә хезмәт, сызым дәресләрен яратып укыттым. Аларның бетерелүе бик кызганыч, әлбәттә. Элек мәктәптәге бөтен эшләрне хезмәт укытучысы эшли иде бит. Менә яңа уку елыннан кертмәкче булалар да, тик ничек булыр ул – билгесез, чөнки күп әйбер таралып бетте инде, – ди оста.

Хәзерге вакытта исә Илдар абый өстәлләр, урындыклар, эскәмияләр, агачтан тәрәзә өлгеләре, кухня кирәк-яраклары, савытлар ясый.

– Мин имән белән эшләргә яратам, чөнки ул нык, чыдам агач булып санала. Моннан тыш, рәсемнәре бик матур, махсус ясаган төсле. Чималын Казаннан барып алып кайтам. Минем туганымның кухнялар ясау буенча үз бизнесы бар. Алар өчен дә шактый җиһазлар ясадым. Ә менә бу эпоксид сумала кулланган өстәлне бик озак ясарга туры килде. Башкаларга да эшләр идем, тик җылы урын булу кирәк. Сумала салкында куера, – ди ул.

Илдар Маликов әйтүенчә, агач материалга тиңнәр юк. Ул сәламәтлеккә дә яхшы, матур да, тик, кызганыч, аның модасы чыгып бара. Элек агачтан эшләгән әйберләрнең күпчелеген хәзер тимердән эшлиләр.

– Агачның җаны бар аның. Элек, мәктәптә эшләгән елларда, халык чират торып алып бетерә иде ясаган әйберләремне. Эшләп өлгертә алмый идем. Шәһәрнекеләр күбрәк кызыксынса да, авылда яшәүчеләргә ул кызык түгел. Дөресен әйткәндә, хәзер аның белән акча да эшләп булмый, чөнки агач кыйммәт, ә хезмәте түбән бәяләнә. Ике-өч ел элек бер урындыкны 800 сумга саткан булсам, узган ел 1 мең сумга эшләдем. Кулга акчасы бик аз кала. Безнең авылда агач осталары бик күп иде, табыш китерми башлагач, күпләр башка һөнәр үзләштерде, – ди Илдар абый.

Менә шулай остазлык үрнәге генә күрсәтеп калмыйча, осталык серләренә дә төшендерә алган Нияз Маликов улын.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 2095 данә
Гомуми тираж – 11293 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 234

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+